**Мөхәммәтшин Г.С.**

Робагыйлар бакчасы

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М98

**Мөхәммәтшин Г.С.**

Робагыйлар бакчасы: робагыйлар / Гарифҗан Мөхәммәтшин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 191 б. — 2000 д. —
ISBN 978–5–298–01593–6

Балтач төбәгендә яшәүче танылган шагыйребез Гарифҗан Мөхәммәтшинның бу китабында аның гомер буена туплана килгән робагыйлары урын алды.

ISBN 978–5–298–01593–6
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Мөхәммәтшин Г.С., 2007

# Гамьле шагыйрь бакчасы

Исемнәре татар әдәбиятында безгә мәгълүм Мөхәммәтшиннар өчәү: Галим(җан) Мөхәммәтшин (1911–1938), Газиз Мөхәммәтшин (1932–1972) һәм Гарифҗан Мөхәммәтшин (1941). Пәйгамбәр исеме белән бәйле бу затларның икесе иҗатлары үрләр чакта яшьли дөньядан киткән. Шулай да Галимҗан дигәне — 30 нчы елларда, Газизе 60 нчы елларда әдәбият тарихында азмы-күпме эз калдыра алганнар. Ә Гарифҗан Мөхәммәтшин — безнең замандаш, кырык еллап әдәби-мәдәни хәрәкәттә актив катнашып килүче каләмдәш. Күпләребездән аермалы буларак, ул үз төбәгендә, туган туфрагында яшәп иҗат итә. Озак еллар җитәкчелек эшендә булды. Әмма табигате-асылы белән педагог-тәрбияче ул. Аның иҗади кредосы — кешеләргә күбрәк яхшылык эшләү, аларда күркәм сыйфатларны үстерүгә булышу, дөньяда иманны һәм ямьне арттыру... Ул — унлап китап авторы. Алар арасында балалар-үсмерләргә атап язылганнары да, өлкәннәргә адресланганнары да бар.

Гарифҗан Мөхәммәтшин соңгы елларда Балтач төбәге тарихын өйрәнде, зур күләмле энциклопедик хезмәт чыгарды. Мондый җаваплы эштә автордан тикшеренүче галим булу да сорала. Бу җәһәттән аны галим-шагыйрь дип тә санап була. Балтач төбәгеннән чыккан яшь каләм ияләренең иҗади үсешендә дә Гарифҗан Мөхәммәтшинның хезмәте хөрмәткә лаек. Яшь иҗатчылар өчен чын мәгънәсендә остаз әдип ул. Киң катлау укучылар аны тынгысыз публицист сыйфатында да яхшы беләләр. Көндәлек матбугаттагы даими чыгышлары шуны раслый. Соңгы елларда иҗат иткән эссе-парчаларын да истә калырлык яхшы әсәрләр дип исәплим мин. Шулай итеп, безнең замандаш Мөхәммәтшинıбыз кеше буларак та, иҗатчы буларак та, язмышы белән элгәрге Мөхәммәтшиннардан бәхетлерәк булып чыкты.

Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Робагыйлар бакчасы» дип аталган бу китабы тулысы белән дүртьюллык шигырьләрдән тора. Үзем дә, шигъриятнең кыска формаларына битараф булмаганга күрә, бу шигырьләрне аеруча кызыксынып укыдым. Ошый миңа кыска шигырьләр. Хикмәтле булганнары бигрәк тә! Гомумән, татар шигъриятендә кыска формаларның үсештә булуы сөендерә. Аз сүз белән җитди фикерләр әйтә алу әдәбиятның җитлеккәнлеген билгели, әдипләребезнең профессиональ осталыгын күрсәтә. Димәк, шагыйрьләр сүзнең куәтен тулы җегәрендә файдалана беләләр. Хәзерге шагыйрьләрнең, яше булсын, өлкәне булсын, кыска шигырьләргә мөрәҗәгать итмәгәне юк та бугай. Әгәр элегрәк чорларга кайтып, әйтик, үткән гасырның 50 нче елларында чыккан шигырь китапларын укып карасаң, нигездә, эчпошыргыч озын шигырьләргә, су буе озын поэмаларга тап буласың. Шөкер, хәзер вазгыять бөтенләй бүтән. Заман таләбе — кыскалык, төгәллек, тирәнлек. Гарифҗан Мөхәммәтшин бүгенге яшәү ритмын яхшы тоеп, заман егете булып иҗат итә.

Әйтә белүнең, бу очракта кыска формаларда бәян итүнең дә төрле ысуллары бар бит әле. Берәүләр икеюллыкның классик камил сурәтен таба, берәүләр, чәчәклардән экибана ясаган кебек, иректә форма сайлый. Кем ничек булдыра ала да, укучы кемне үз итә. Соңгысы — Вакыт хөкемендә.

Гарифҗан Мөхәммәтшин кыска форманың гасырлар буе сыналган робагый вариантын сайлаган. Робагый язуның отышлы ягы белән бергә сагайта торган ягы да бар. Бик күп бөекләр таптаган юл бит, анда үз сукмагыңны сала аласыңмы? Чыннан да, мәгълүм тар кысаларда яшәеш фәлсәфәсенең киң төсмерләрен (яңасын!) табарга кирәк бит! Көнкүрешнең артык вак детальләрен дә бик үк өнәми бу форма. Бүгенге көндә робагыйлар язарга алыну үзе бер тәвәккәллек.

Үрнәк өчен шагыйрьнең берничә робагыен китереп узыйк:

Өзгәләнеп җилләр исә Болгардан —

Ерак калган әрнү тулы еллардан,
Шушы җилләр кагылу белән моң саркыла
Йөрәктәге киеренке кыллардан, —

дип, халкыбызның фаҗигале язмышы-тарихы турында уйлана. Шагыйрьне яшәешнең һәр проблемасы борчый, сызландыра.

Үрсәләнмә әле, йөрәк, дөнья чуар,
Бетеп бара Кеше җанын аңлаучылар,
Ара-тирә үсмер чактан йомшак кешнәп,
Нихәл, диеп сорый бары Алмачуар, —

дип, бүгенге тормышыбыздагы ваклык-түбәнлекләр өчен көенә. Ә менә бу юллар Кешелек дөньясының мәңгелек рухи сугаручысы булган изге мәхәббәт хисе турында:

Күзләреңә бактым — күзем алалмадым,
Тик әйтергә сүзләр генә табалмадым,
Алдыбызга өзелеп төште кызарып пешкән
Бер алмасы бакчадагы багалманың.

* * *

Җырлый-җырлый сандугач та картаямы?
Унсигездә күзең төшкән яр каямы?
Кинәт кенә шул сораулар килде башка —
Әллә инде минем баш та «янтаямы»?!

Әлеге юлларда тирән киная, үтә кырыс җаннарны да елмайтырлык юмор хисе ялтырап ята.

Өстәлләрдә касә тулы шәраб тора,
Күзен кысып миңа гына карап тора,
Шәраб эчеп, хурлар кочып гомер итү
Өч мизгеллек бу дөньяда ярап тора.

Бу китапка Гарифҗанның 800 ләп дүртьюллыгы кергән. Бик зур сан. Аларның байтагы, көндәлек матбугатта басылып, укучыларга иреште дә инде. Күпмедер сынау үтте дип әйтүем. Автор бу китапта аларны унлап төркемгә бүлеп урнаштырган. Болай эшләү, ягъни авторның дөнья, яшәеш турындагы фикерләрен шулай төрле фокусларга туплап бирү — шагыйрь белән укучы арасында араны якынайта, аңлауны җиңеләштерә. Ихтимал, ул төркемнәр фикер җегәрлеге җәһәтеннән тигез түгелдер, кайбер робагыйларның урыны үз төркемендә булмавы да бар. «Робагыйлар бакчасы» аллеясында төз нарат кебек, ыспай басып торганнары арасында кәрләләре дә бардыр... Вакыт үтәр, табигый сайланыш үз эшен эшләр. Бәлки, сигез йөз саны сиксәнгә үзгәрер. Сайлар өчен иң әүвәл мөмкинлек кирәк. Ә китапта андый мөмкинлек бар.

Гарифҗанның бу китапка тупланган робагыйларын укыганда аның туган телебезне тирән белүенә сокланмый мөмкин түгел. Инде телебездән төшеп, югалып бара торган сүзләр, гыйбарәләр аның шигырьләрендә якты җәүһәр кебек балкып китәләр, телебезнең байлыгы, матурлыгы... язмышы турында уйландыралар.

Тирән фәлсәфи уйлануларга бай бу китапны укыгач, Гарифҗанның ихласлык һәм иманлылык иясе булуына сөендем. Шагыйрь өчен бик тә кирәк сыйфатлар болар. Авторның үзе белән таныш булмаган кеше дә, аның шигырьләрен укыгач, шагыйрьне, аның эчке дөньясын, кичерешләрен бөтен тулылыгы-барлыгы белән күз алдына китерәчәк. Һәрхәлдә, шәхсән үзем шагыйрьне яңадан бер кабат ачтым, җанының зурлыгына, күңеленең байлыгына тагын бер кат инандым. Милләттәшләр, чордашлар гына түгел, фикердәшләр дә икәнбез бит! «Робагыйлар бакчасы»нда күңелгә хуш байтак «гөлләр» өздем, яшәеш турында янә кайтып уйландым, вакытның кадерен белеп, дөньяны ямьләрлек дәрәҗәдә иҗат итү хисе көчәйде. Укучыларның да шундый татлы халәт кичерүләрен телим.

*Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык шагыйре*
*Апрель, 2007*

# Укучыма бер сүз

Кеше җаны гамьсез була аламыни — уйлана ул, моңлана, сызлана, әзләнә. Яшәешнең бар шаукымы кеше җаны аша үтә ич, кеше җанын кыбырсыта, тынгысызлый. Аннан соң, кеше гомеренең дә үз фасыллары бар ич аның, нәкъ еллар кебек — язы бар, җәе, көзе, кышы бар. Гомер фасылларының һәркайсында күңел гамьнәре дә төрлечә.

Мин бакчада казынырга, агачлар, гөлләр үстерергә яратам. Кеше күңелен, кеше җанын гөлләрдән дә тирәнрәк аңлаучы юктыр ул. Язмыш җилләре кая гына илтеп төпләндерсә дә, иң беренче булып бакча булдырырга, гөлләр, чәчәкләр утыртырга тырыштым. Күп утырттым, күп үстердем мин гөлләрне дә, агачларны да...

Монысы менә робагыйлар бакчасы. Анда минем гомеремнең төрле фасылларында шытып чыккан, үсеп җитеп бөреләнгән, чәчәк аткан күңел гөлләрем — күңел гамьнәрем. Беләм, арасында «бөреләнми генә» чәчәк атканнары да бардыр, кырау өткәне дә. Нишләтәсең, бакча бит инде ул...

Кыскасы, кадерле укучым, мин Сине үземнең менә шушы күңел бакчама — робагыйлар бакчасына чакырам. Андагы бер чәчәк кенә булса да, Синең күңел гамьнәреңә тәңгәл килеп, Синең җаныңны яктыртса, мин шат булырмын. Миңа шуннан башка берни дә кирәкми!

* * *

Робагыйлар язу хәзер мода, диләр,
Шуңа ияреп мин дә яздым робагыйлар,
Тәнкыйтьчеләр күрмәсәләр күрмәс, әйдә,
Укыр әле дус-иш, кода-кодагыйлар.

* * *

Бер уйласаң, бу тормышта бары да гади —
Берәү Мәҗнүн, берәү Нәби, берәү Гали,
Мәҗнүннәр дә, Нәбиләр дә, Галиләр дә
Нигә икән бер үк ташка абынгалый?

* * *

Табигатьнең бар мәңгелек үз гаме —
Берни түгел аңа гомер узганы,
Оран сала әллә кайдан, тирәннән
Мең-мең язмыш күмгән еллар тузаны...

* * *

Сикереп кенә менәр идем юргаларга,
Очып кына кайтыр идем Урдаларга,
Бәгырь сыкрый авыр чакта яу кырында
Бабамнарның сафларында булмаганга...

* * *

Өзгәләнеп җилләр исә Болгардан —
Ерак калган әрнү тулы еллардан,
Шушы җилләр кагылу белән моң саркыла
Йөрәктәге киеренке кыллардан.

* * *

Талгын гына агып ята агымсулар,
Агымсуга баккан күзләр аһ моңсулар,
Моңсу күзләр, агымсуга баккан килеш,
Гомер юлын әле шулай мең кат урар.

* * *

Яшәү бит ул гап-гади бер узыш-ярыш,
Шул узышта калышмыйм дип чабып барыш,
Финишка да калган инде тик бер карыш —
Бирешмә, дим йөрәгемә, карыш, карыш!

* * *

Бу юллардан инде ничә буын узган —
Хыялланган, сөйгән, көйгән, җырлар сузган...
Кылганнарның ярсынуын карап торам —
Алар чаба ярсып-шашып, купмый тузан.

* * *

Ярларына кайта инеш ташый да,
Идел булам, дип, ярларын ашый да...
Язгы инеш хыяллары ничә кат
Әйләндерде безнең исәр башны да.

* * *

Җилләр исә — җылы җилләр шәрыктән,
Җилләр исә — салкын җилләр гаребтән,
Безнең җаннар болай да бит корышкан,
Җылы җилләр юлла безгә, фәрештәм...

* * *

Хәятыңда аера бел ак-караны,
Кара белән озакка сузмый өз араны,
Яугирләрнең ише була алмасаң да,
Җәлладларның була күрмә син яраны.

* * *

Кылычыңны кынысыннан уйлап чыгар —
Кире тыксаң, куркак дигән даның чыгар,
Кынысыннан чыккан кылыч кире керми,
Йә җиңәр ул, йә орышта чатнап сынар.

* * *

Ничәмә күз күктән безгә карап тора,
Кылган һәрбер гамәлеңне санап тора,
Яшен булып йөрәгеңне чыбыркылый,
Күкрәү булып кисәтә ул, тамак кыра...

* * *

Кайчакларда җор булам мин — Әлмәндәрме,
Кайчакларда хәтерләтәм Пәйгамбәрне,
Әлмәндәр дә, Пәйгамбәр дә булып, йөрәк,
Ахыргача барыр синдә дәрман бармы?

* * *

Картайдыммы, уйлыйм һаман балачакны,
Һич уйламыйм тәмугларда яначакны,
Бу дөньяда бәгыремне өшеткәннәр
Анда миңа кайнар учак ягачакны...

* * *

Малай чакта безнең хыял атлар иде,
Бәйгеләрдә урын бирмәс чаптар иде.
Бәйге үткән, атлар беткән бу заманда,
Абзыкаем, хыялыңа атлан инде...

* * *

Чишмәләр челтерәп ага гел тынмыйча,

Кышларын зәмһәрир салкында туңмыйча —
Кыендыр үтүләр бу тормыш юлларын
Чишмәләр шикелле туңмыйча, уңмыйча.

* * *

Балачактан китә алмыйм гомер буе,
Аннан соңы яшәү түгел, шайтан туе,
Әллә көзе җитеп килә гомеремнең —
Кояш сүрән, җилләр ачы, болыт куе...

* * *

Гомер бит ул тора бары минутлардан,
Кайсы минут кайнарырак мең утлардан,
Күпме гомер үтте икән ялварып,
Бер тамчы су бир, дип аккан болытлардан.

* * *

Яшь чакларда күңел күккә җилкенә —
Эләгә ул исәр хисләр иркенә,
Белми әле, тауга карап йөгергәннәр
Тигез җирдәге түмгәккә сөртенә.

* * *

Бу дөньяга килгәнбез без кунак булып,
Яшик әйдә ипле генә, тыйнак булып...
Биргән идем бер дустыма шундый киңәш —
Кылыч алды башкаемны кыймак булып.

* * *

Кайсы елы, көне кайсы гасырның —
Ачар берәү яшәешнең асылын
Һәм китәр ул мәңгелеккә бу дөньядан,
Тыя алмый йөрәгенең ярсуын.

* * *

Бу дөньяда миңа инде бары да таныш —
Челтер-челтер ага сулар, шаулый камыш...
Аккан сулар, искән җилләр, иңрәү күкләр,
Сезгә багам эзли-эзли яңа табыш.

* * *

Үрсәләнмә әле, йөрәк, дөнья чуар,
Бетеп бара кеше җанын аңлаучылар,
Ара-тирә үсмер чактан йомшак кешнәп,
Нихәл, диеп сорый бары Алмачуар...

* * *

Борма-борма бу тормышның юллары —
Сызган аны кырыс язмыш куллары,
Шул юллардан тайпылырмын дип уйлама,
Барыбыз да шул язмышның коллары.

* * *

Бу офыклар әллә ничек тылсымлы ла —
Күңелләрне әллә кая ымсындыра,
Күңелләрне еракларга ымсындырып,
Язмышларны сыный-сыный мең сындыра.

* * *

Утны-суны кичкән буын китеп бара,
Әкрен генә безнең картлык җитеп бара,
Күңелләрне өтәли гел тынгысыз уй —
Бездән дөнья өтек кала, өтек кала, өтек кала...

* * *

Кара төннәрдә атылган йолдыз кебек,
Күңелдәге ак өметләр бара сүнеп,
Без китәбез, сез каласыз, дигәннәргә
Әкрен-әкрен безнең күңел килә күнеп.

* * *

Гомер үтте бар ялганны чынга алып,
Алданганны аңлап алдык соңга калып,
Ә югыйсә рәхәт иде яшәүләре
Ялтыравык ялган белән ялкынланып.

* * *

Күтәрә язмыш кайчак биек орбитага,
Кайчак кача, упкыннарга ыргыта да,
Кайчагында борылып та карамый ул,
Бу дөньяда барлыгыңны оныта да...

* * *

Күңел һаман хакыйкатькә юллар эзли,
Юллар эзли, табарына өмет өзми,
Хакыйкатьнең ялган белән буталганын
Әллә белми, әллә күрми, әллә сизми.

* * *

Шатлык тәмен белеп булмый кайгы күрми
(Йөзәргә өйрәнеп булмый суга керми),
Хәят тора шатлыклардан, кайгылардан —
Кайгысы да, шатлыгы да ялгыз йөрми.

* * *

Егерменче гасыр мең кат алдады,
Нинди генә йөкләр иңгә салмады,
Яңа гасыр ишек ачты киң итеп —
Йөк тартырга дәрман гына калмады.

* * *

Омтылмый бүген безнең җан аклыкларга,
Битараф без кайгыларга, шатлыкларга,
Туймас нәфес, сары металл, яшел елан
Әверелдерде барыбызны маңкортларга...

* * *

Балачакта гомернең иң гүзәл чагы,
Егет булгач — типсә тимер өзәр чагы,
Картайгачтын бала чагын, егет чагын
Һәр көн саен хәтерендә гизәр чагы.

* * *

Бүген беркем дә уйламый үләсен,
Беркөн язмыш каһкаһәләп көләсен,
Сөяк куллы Газраилнең иркәләп
Ябык тәнен ак кәфенгә төрәсен...

* * *

Өзгәләнә кайчак йөрәк юкка да,
Шул юк-барлар сала аны утка да,
Күпме генә өзгәләнсен йөрәк шулай —
Җир йөзендә барыбер хәсрәт-ут кала...

* * *

Ни күрәсен мөмкинме соң тәгаенләү —
Тормыш йөкне сорамыйча сала иңгә,
Егет кеше сер дә бирмәс, сынатмас та,
Сыкранмыйча тартыйк әйдә, агайнеләр.

* * *

Китүчеләр була мәңге кайтмый торган,
Югалтулар була бүтән тапмый торган,
Була тагын югалткач та истәлеген
Гомер буе йөрәкләрдә саклый торган...

* * *

Гыйбрәт итеп көлә халык ахмактан,
Ахмак булып бизүчедән әхлактан,
Халык шулай күп гасырлар дәвамында
Үз әхлагын ахмаклыктан пакьләткән.

* * *

Әй бу көзнең җанга баскан томаннары,
Китеп баручы кошларның ораннары...
Әле дә ярый алда язлар киләсе бар —
Шул көч бирә яшәтергә бу җаннарны.

* * *

Бу дөньяның фанилыгын күреп торам,
Мыек астан гына карап көлеп торам,

Һәр үткән көн бакыйлыкка якынайта —
Үткән көнем саен бармак бөгеп торам.

* * *

Көннәребез үтә безнең зар белән,
Канәгатьләнә белмибез бар белән,
Юкса дөнья чүп-чарлардан арыналмый
Кычкырудан җыелышып хор белән.

* * *

Төн караңгы булган саен, йолдыз якты —
Кара төсләр җете итә һәрчак акны...
Әй, Гарифҗан, ни әйтергә теләвең бу,
Кара төскә мәдхияләр җырлар чакмы?!

* * *

Нәрсәнедер югалттым дип үкенмә,
Табып бир, дип Аллаһыдан үтенмә,
Кемдер табар һәм сөенер табышына,
Ул фәкыйрьнең сөенечен үтермә!

* * *

Бабайларда булган изге хасият —
Улларына калдырганнар васыять,
Уллар сорый хәзер акча калдыруны,
Хасиятең, васыятең — анысы ят...

* * *

Без китәбез, дөнья кала кемнәргә,
Әйләнмәсме яшәү кара төннәргә?..
Шундый уйлар килеп күздән йокым ала,
Башны салу белән кичен мендәргә.

* * *

Гади генә киңәш бирәм, орышма,
Бу дөньяны аңлармын дип тырышма,
Урының булсын һәрчак алтын урталыкта —
Яшәешнең агышыннан калышма...

* * *

Хәсрәт дәрьяларын, беләм, кичтем инде,
Ширбәт диеп күпме агу эчтем инде,
Тагын нинди «сыйларың» бар, әй язмышым,
Калган гомер, саный калсаң, өч көн инде...

* * *

Кешеләрне дөнья буйлап язмыш йөртә
(Язмышларга булмый икән куеп киртә),
Бер тамчы су бирегез, дип ялварганда,
Кайнар утлар уртасына төртеп кертә.

* * *

Бу дөньяны чиккән кеше чикләр белән,
Шул чикләрне саклый хәзер чукмар белән,
Бизәргә иде Җирне чәчәк-чуклар белән,
Ызгыш эзли, талаш эзли юк-бар белән.

* * *

Ничә кабат җанын пешереп
Сугыш-сугыш уйный кешелек,
Шулай дәвам итәр, ахры, үз өстенә
Дөнья тетрәп коелганчы ишелеп...

* * *

Меңләгән һөнәр бар җирдә, берсе — җәллад,
Гомер буе баш кисә ул, тормый җәлләп,
Җан акларга бар аның да үз дәлиле —
Бара торсын, бу дөньядан рәхәт җәннәт!

* * *

Азмы җирдә аһ-зар эчкән бәхетсез,
Иң бәхетсез — хаким, калса тәхетсез,
Тәхетен җуйган хаким аһ-зарына
Ничә кабат булдык шаһит без!

* * *

Бу җиһанда эзе калган бик күпләрнең —
Еланнарның, шакалларның, бөркетләрнең...
Арабызда еланнар күп, шакаллар күп,
Күрми күңел яктылыгын ак күкләрнең.

* * *

Шөкер итә белми кеше барына,
Яңа барлар кирәк барның янына,
Барысының өелеп җирдә калачагын
Аңлый бары җиткәч упкын ярына.

* * *

Әйләнә Җир, аның мәңге туктасы юк,
Туктар иде — таянырга ноктасы юк,
Тотып алып учка салып бер җылытыйм
Дияр идем, тотар өчен тоткасы юк...

* * *

Гомеремдә тапкан олы ачышым —
Җирдә яшәүләре, ай-һай, ачы соң!
Яшәү диеп әллә язмыш каптырамы
Шәрабларга кушып агу тамчысын?

* * *

Һәр көн саен арта бара югалтулар,
Юатма син, кирәк түгел юатулар,
Югалтулар арткан саен янәшәдә,
Авырая бара икән юл үтүләр.

* * *

Туганда ук безнең акыл булмаган —
Кире кайтып китәсе иде дөньядан,
Татар акылы һаман арттан йөри —
Без туганда ул булгандыр тумаган!

* * *

Кемнәргәдер якты дөнья тар кебек,
Аннан да киңрәк бер җиһан бар кебек.
...Яңа каләм сатып алдым әле бүген —
Шул каләмдә яңа илһам бар кебек!

* * *

Уңга карыйм, сулга карыйм — коймалар,
Таштан, кирпечтән, тимердән коялар,
Йортларны да, җаннарны да бер-береннән
Аерып куйган үтәлмәслек кыялар...

* * *

Чит күрә гел күңелем минем вокзалларны,
Күргәнем юк алар кебек ят залларны,
Ничек кенә күтәрәдер диварлары
Аерылу-озату кебек аһ-зарларны?

* * *

Мең адашып акыл эзли кеше гомер-бәдан,
Таба алмый китә дөньядан,
Чөнки әле һәрбер акыллыга төкрек чәчеп
Акыл сата бездә ун надан.

* * *

Елан белән күрешкәндә үбешмиләр,
Бүре белән кочаклашып күрешмиләр,
Тик бармы соң күрешкәнче, үбешкәнче
Кемнең елан, кемнең бүре икәнлеген белүчеләр?

* * *

Гөлдән гөлгә очып йөри күбәләк,
Мин утырам аңа карап чүгәләп —
Бу дөньяда тик күбәләкнең хәяты
Яңа аткан чәчәк кебек түгәрәк.

* * *

Аяз күктә тилгән оча тычкан эзләп,
Болын буйлап төлке чаба тилгән күзләп,

Аучы тора шул төлкегә мылтык төзәп —
Йөрмә «дөнья — түгәрәк» дип дәлил эзләп!

* * *

Бөреләнми чәчәк ата кайбер «гөлләр»,
Җимешләнә алмый алар, өтә җилләр...
Бөреләнми генә туды бу робагый...
Тфү-тфү, нәрсә сөйлим соң мин җүләр!

* * *

Күпләр бүген рекламалый зәңгәрлеген,
Зәңгәрлекнең мәхәббәткә тәңгәллеген,
Ничек кенә диеп зурлыйм сезне бүген,
Зәңгәр күгем, зәңгәр күлем, зәңгәр гөлем?

* * *

Авыр юллар үткән чакта иңдәш кирәк,
Көрәш-мәйдан тоткан чакта тиңдәш кирәк,
Иңдәшеңне, тиңдәшеңне табар өчен
Үз вакытында җанга төпле киңәш кирәк.

* * *

Булмаса да мактанырлык дәү эшләр,
Саналган инде безнең бар табышлар,
Нигә әле безне болай оныттың, дип
Бармак яный югалтулар, ялгышлар...

* * *

Җир әйләнә орбитасы буйлатып,
«Табан»ыннан очкын-йолдыз уйнатып,
Бездән соң да әйләнерме ул шулай, дип,
Кайчагында шомландыра уйлатып.

* * *

Сүз бәясе бәйле була кем әйткәнгә,
Асыл сүз дә төссезләнә күп әйткәндә —
Әйтер сүзең үлчәп сөйлә, дигән халык,
Тик үлчәвен була икән кайдан табып?!

* * *

Мин бәхетсез, диеп һич тә үкенмә син,
Башкаларның бәхетләрен күпсенмә син,
Үз бәхетеңнән олы бәхет юк дөньяда —
Язмыш биргән шул бәхеткә күз тимәсен.

* * *

Мәкерлеләр эзли агу тамчысын,
Җәллад барлый кылыч, балта, камчысын,
Шагыйрь көн-төн энҗе тезә сүзләрдән —
Ул бит дөньяда сәгадәт сакчысы!

* * *

Иртә-кичен көн дә саен Коръән укыйм,
Берәм-берәм җанымдагы чүпне утыйм
Һәм терелтәм ялкынлана алмый яткан
Күңелемдәге сүнәр-сүнмәс иман утын.

* * *

Үткән еллар, сүткән юллар, кайда сез,
Кайтыгыз сез, күңелем сезгә дәгъвасыз,
Каршыгызда тезләнеп бер гафу сорыйм
Үткән гомерләрем өчен кәгъбәсез...

* * *

Караңгы дәверләр булган — иманлы,
Заман хәзер якты — җаннар томанлы,
Утлар гына яктырталмый икән
Еллар буе томаланган бу җанны.

* * *

Сүнәм дигән чакларында йөрәкнең,
Күз алдыма Син киләсең, йә Раббым,
Әллә мине үтә сөеп яраттың,
Әллә инде хәсрәт өчен ялгыттың...

* * *

Чаба гомер бәйгедәге чаптар кебек,
Юлда булса, Иблисне дә таптар кебек,
Шуның белән зая узган гомерләрнең
Бар бушлыгын, бар гөнаһын аклар кебек...

* * *

Дөньяга килгәнбез китәргә килешеп,
Вәгъдә — иман, үтәмичә ни эшлик,
Бүтән инде алданмабыз, бакый йорттан
Китәргә дип килешмәбез һичничек!

* * *

Сөйләмә, дип, энем, тузга язмаганны,
Безнең халык әллә тузга язмаганмы?
Тузга язылган сүзләргә колак салмый
Йөзләр-меңнәр әллә юлдан язмаганмы?!

* * *

Яшь чакларда кесәң тулы доллар кирәк,
Ташпулатлар, «Мерс», кызыл маллар кирәк,
Килә бер көн — гөнаһларың ярлыкауны
Сорар өчен баш очында Аллаһ кирәк.

* * *

Бездән соң да сулар агар, җилләр исәр,

Кошлар сайрар, таңнар атар, гөлләр үсәр,
Тик җәһәннәм утларына егылмыйча
Безнең башлар ничек кенә сират кичәр?

* * *

Тыңлыйм йөрәгемнең тибү тавышларын,
Көтә-көтә гомеремнең баешларын,
Дөп-дөп итеп нидер саный йөрәк —
Саный кебек гөнаһ-ялгышларым...

* * *

Борынгыдан безгә мирас кыйммәтләр бар,
Тәңре безгә бүләк иткән нигъмәтләр бар,
Шуларны да азсынганнар язмышында
Уйланганга акыл алыр гыйбрәтләр бар.

* * *

Кем өчендер җирдә яшәү уендыр,
Кемнәргәдер ачы газап, кыендыр,
И Ходаем, гаҗизләргә сыең бир,
Кеше туган, гаҗизләрне сыендыр.

* * *

Җирдә яшәү, мин аңладым, уен гына
(Уйламагыз бу дип синең уең гына!),
Шул ачышны ясагандыр инде күпләр,
Әҗәл килеп кулын салгач муенына.

* * *

Кояш авышты офыкка — байыйдыр,
Моңсу гына инеш ага каядыр,
Инеш кебек тып-тын гына ага гомер,
Тик күбесе үтә аның заядыр...

* * *

Уйсыз-моңсыз яшәүчеләр бардыр ул,
Уйсыз-моңсыз яшәү ширбәт-балдыр ул,
Андый хәят миңа ләкин кирәк түгел,
Андый дөнья төрмә кебек тардыр ул.

* * *

Бу дөньяга иңде яэҗүҗ-мәэҗүҗләр —
Адым саен сүнгән йөзле гаҗизләр,
Саклый алмадыгыз иманны, дип, безгә
Рәнҗемәгез, әткәй-әнкәй — газизләр.

* * *

Берәүләрне күмә язмыш зур данга,
Берәүләрне илтеп тыга зинданга...
Мәңгелек йортыгыз менә шушында, ди,

Зират каенына козгын кунган да...

* * *

Бу язмышлар бигрәк шаян, шук икән,
Ул вәгъдә иткән бәхетләр җирдә юк икән,
Барын табарсың бакый дөньядан, ди,
Андагысы — ачы, кайнар ут икән...

* * *

Гомер үтте башны иеп түрәләргә,
Кыйбла тотып алар әйткән сүрәләргә,
Күңел дә буш, кесә дә буш, өстәл дә буш,
Кыйблабызны борыйк башка тирәләргә.

* * *

Яши-яши аңладым мин, туганнар,
Бу дөньяны артык шашып куганнар
Үз максатына ирешми адашып
Кыйблаларын, иманнарын җуйганнар.

* * *

Беркөн килеп Әҗәл керер ишек ачып
(Минем ишек кем керсә дә һәрчак ачык),
Тынгы бирми вәсвәсәле бер уй гына –
Урының бармы ул килгәндә калыр качып?

* * *

Бар әле, бар, без менәсе үрләр бар,
Аяк бөкләп утырасы түрләр бар,
Үрләр яулап, түрләр даулап арыгач,
Тыныч кына кереп ятар гүрләр бар...

* * *

Ялгыз агач ышыгы ул күпләрнең,
Шул ошамый калебенә Күкләрнең,
Чөнки күпләр арасында — җен дә шайтан...
Яшен суга ләкин агач күкрәген!

* * *

Юл йөргәндә сөртенәбез түмгәккә,
Гомер кичкәндә — эшлексез, имгәккә...
Нәрсә диеп бәя биргән икән, туган,
Бу халәткә изге китап — Сөннәттә?

* * *

Барган идем мәзәкчеләр мәҗлесенә,
Тик эләктем әләкчеләр мәҗлесенә —
Шунда күрдем мәзәкләрнең иң мәзәген,
Бу дөньяда эш калмаган, Иблис, сиңа!

* * *

Чиксез күктә балкыйм, дидем йолдыз булып,
Каплады күкне килде дә кара болыт,
Күк күкрәде, җир тетрәде, ишеттем өн —
Яшә, диде, язмышыңа дога кылып.

* * *

Дөньялыкта кемдер байый, кем бөлә,
Кемдер елый әрни-әрни, кем көлә...
Бакый дөнья көтеп тора барыбызны —
Анда баргач ничек булыр, кем белә?..

* * *

Дөнья кала, китәбез, дип йотма ут,
Бу дөньядан китми калган кем дә юк —
Вакытында киталмаган бәндәләргә
Дөньялыкта хөрмәт тә юк, көн дә юк.

* * *

Бу дөньяга кеше сыя, сыймый нәфес,
Нәфес колы микән әллә һәрбер шәхес?
Нәфес дигән Газазилдән җанны саклый
Ала бары илаһи моң, иман вә хис.

* * *

Озата-озата гасыр арты гасырын
Эзли кеше җирдә яшәү асылын,
Югыйсә бит яшәү асылы — язмыш үзе,
Ә язмышың — Ходай биргән насыйбың.

* * *

Безнең заман тора тоташ үзгәрештән
(Иртәгә дип ният кылма бүген кичтән!),
Ул үзгәрде, бу үзгәрде, теге үзгәрде,
Тик син генә үзгәрмәче, әй, фәрештәм!

* * *

Сулар юар бу бәдәннең карасын,
Вакыт сихәтләр җаннарның ярасын,
Кемнәр табар вөҗданнарның төбендәге
Меңьеллык караны юу чарасын?!

* * *

Гомерне без һич тә сатып алмаган,
Ул тик бүләк безгә Илаһ Алладан —
Мизгелен дә уздырмыйкчы заяга,
Ул бер генә, яшәп булмый яңадан!

* * *

Язмышларны ватып ташлый ялгышулар
(Боргаланмый гына акмый агымсулар!),
Боргаландык та болгандык агымсудай —

Ярлыкасын инде безне бары Ходай...

* * *

Күңелемдә кайный минем утлы җиһад —
Яхшы-яман якалаша көнгә ун кат,
Гомер буе җиһад кичкән инсаннарның
Җәннәт түрендә урыны, дигән Китап.

* * *

Кергән чакта гомерләрнең көзләренә,
Көзге җилләр үткән чакта үзәгеңә
Колак салып газиз әткәй сүзләренә,
Бер багасы килә әнкәй күзләренә...

* * *

Бәргәләндем гомер буе дулкыннарда,
Дулкыннары илтеп салды упкыннарга,
Дулкыннарны-упкыннарны кичеп бүген
Чәбәләнеп ятам менә салкын ярда.

* * *

Гомер үтә, еллар эшли үз дигәнен —
Берәм-берәм чүпли гомер мизгелләрен:
Үткәннәрен изгелектә, исәрлектә...
Хәтер саклый күбрәк аның изгеләрен.

* * *

Бар кешене тиңләдем мин игезләргә —
Омтылдым гел бу дөньяны тигезләргә,
Тик юлыктым шул дөньяны тотып торган
Үгезләрдәге дәһшәтле мөгезләргә.

* * *

Омтылдым гел яшәү серен ачарга,
Ачтым — ымсындым ташлап качарга,
Җибәрмәде ләкин нидер, гомер буе
Туры килде бәхетле йөз ясарга...

* * *

Мин әзермен кылыр өчен әллә ни —
Ике яктан ике Иблис, әйдә, ди,
Намусыма ләкин хисап бирәсем бар —
Мин белмим бит намусымны хәйләли.

* * *

Хәятның мин аз күрмәдем артын-алдын,
Күргән саен үз-үземә гыйбрәт алдым,
Әллә шуңа, гомер буе үзгәралмый
Хәятымда гел үз-үзем булып калдым.

* * *

Көлү дигән бер тылсым бар — белдем мин,
Елыйсым килгән чакта да көлдем мин,
Көлү-елмаю белән тик гомер буе
Үз җаныма яшәү көче бирдем мин.

* * *

Юлларыма минем гөлләр түшәлгән,
Нур сибелә зәңгәр күктән — түшәмнән,
Минем күңелем күптән инде шул күкләрдә —
Кабат җиргә мин тиз генә төшәлмәм...

* * *

Бүген белән бетми әле гомерләр,
Иртәгә дә әле яшәр көнем бар,
Ул көнемне сәгадәтле итәр өчен
Гөлбакчамда чәчәк атар гөлем бар.

* * *

Үпкә саклый белмәдем мин кемгә дә,
Башкалардан күбрәк салдым иңгә дә,
Кемнәрнедер үпкәләткән булсам ялгыш,
Мәрхәмәтле булыгызчы миңа да.

* * *

Күңелдәге хисләр оча, ерак китә,
Алар өчен кысан хәтта Галактика,
Хисләремне кабат Җиргә кайтарып
Таң җилләре чәчләремне тарап китә...

* * *

Антей хыялларын ничә кабатладым —
Ничә кат яндырдым хыял канатларым,
Ничә кат егылып җанны канатмадым...
Җанымда мең сорау — тапмыйм җавапларын.

* * *

Рәхмәт инде сиңа, йөрәк, сынмаган өчен,
«Сынма», дигән гозеремне тыңлаган өчен,
Татлы сөю назларында сыйлаган өчен,
Хәтта кайчак күкрәгемә сыймаган өчен...

* * *

Мин яратам сезне — кешеләрне,
Гадиләрне — үзем ишеләрне,
Рухы олы, күңеле кечеләрне,
Сөймим ләкин сүрән, төчеләрне.

* * *

Бу тормыштан беләм күпне алганым,
Белә алмыйм алда күпме калганын,
Язлар җитсә, көз утырткан алмагачның

Арып бетәм көтеп яфрак ярганын.

* * *

Әллә ничек соңлап килде миңа бары —
Акыл-гыйлем, шәрәф-шөһрәт, дөнья малы...
Уйлап йөрим, болай булса мөмкин әле
Картлыкның да соңлап килү ихтималы!

* * *

Мин хәтерлим әнкәемнең безгә әкият сөйләгәнен,
Орчык көенә моңлы җыр көйләгәнен...
Кайвакытта картайгач та күңелләргә
Синең моңлы җырың кирәк безгә, әнием!

* * *

Уңга тартып, сулга тартып йөгәнен,
Бу тормышның җаен тапмый йөдәдем,
Инде таптым диеп кенә сөенгәндә,
Инфаркт, дип хәбәр салды йөрәгем.

* * *

Булмады ла башкалар күк кискен булып,
Үтте гомер әллә ничек мескен булып,
Кемдер — рәис, кемдер — түрә, кем — депутат,
Тик мин генә китәлмәдем һичкем булып.

* * *

Мохтаҗ түгел безнең җаннар алкышларга,
Сәхнәләргә, сәхнәдәге балкышларга,
Түзсен генә йөрәккәйләр ярылмыйча
Бу көндәлек этеш-төртеш, тартышларга...

* * *

Акыллыларга карыйм да гыйбрәт алам,
Батырларга карыймын да гайрәт алам,
Акыллы да, батырлар да түгел, миндәй
Урта куллар күплегенә хәйран калам.

* * *

Гади диеп уйлама, мин гади түгел,
Гали дип тә кабул итмә, гали түгел,
Бу тормышта уңда-сулда мең-мең гөнаһ —
Мин аларның берсеннән дә хали түгел.

* * *

Гомеремдә ничә кабат абындым,
Кеше күрмәсен дип торып кагындым,
Абына-кагына өйрәнәсең икән
Бутамаска, аксатмаска адымың.

* * *

Кайчак сыя минем йөрәк учыма да,
Кайчак галәмгә дә сыймый, очына да,
Тиле икән йөрәге дип уйлама син,
Егет йөрәге ләбаса ул шуңа да!

* * *

Без дә китәрбез беркөнне Мәңгегә,
Сер түгелдер бу хакыйкать мәнлегә,
Тик мин китә алмам кебек бу дөньядан
Фани дөнья Мәңгелектән ямьлегә.

* * *

Бу абзагыз шактый гына акыллы
(Ышанмасаң укы кабат атымны!),
Сүзләремнең хак булуын дәлилләп,
Баш очымда якты йолдыз атылды.

* * *

Яңа гасыр әнә кыю ишек шакый,
Сабый булса да аңлый ул, яшәү бакый,
Ишек ачып дәшәм аны өстәлемә —
Гомер мәҗлесендә бүген мин бер сакый.

* * *

Баш өстемдә йолдыз тулы серле төн,
Йолдыз эзлим үземә — иң серлесен,
Бу күңел һич җуймый әле өметен —
Гүя алда бәхет көтә бербөтен!

* * *

Бер үпкәм юк, рәнҗүем юк Әҗәлгә
(Аны данлап яздым хәтта газәл дә!),
Гөнаһлылар арасыннан сайлап алып
Юллама бирде ул миңа әзәлгә...

* * *

Әткәемнең сүзен тоттым карусыз —
Гомер буе хезмәт иттем арусыз,
Тирләп-пешеп тарттым тормыш арбасын,
Гомер иттем шуңа күрә дарусыз.

* * *

Мәрхәмәтсез язмыш күпме типкәләде,
Йөрәгемне парә-парә теткәләде...
Әй, Гарифҗан, типкәләүләр-теткәләүләр
Әллә инде булды димсең тикмәгәме!

* * *

Ярый әле бу дөньяга туганмын,
Җан-фәрманга чабып дөнья куганмын,
Бүген инде дөнья мине үзе куа —
Кая кереп качыйм икән, туган, мин?

* * *

Гомер буе эзләдем мин үз-үземне
(Биргән инде миңа Ходай түземне!),
Таптыңмы, дип сорама син, туганкаем,
Табалмадым, инде өмет өзелде...

* * *

Мин китсәм дә, хәят бетми, кала ул,
Яңа килгәннәрне утка сала ул,
Калганнардан кыл кадәр дә көнләшмим,
Әҗәл хәзрәт аларны да ала ул...

* * *

Җаным аша ничә яшен үтмәгән...
Бу күзләрем күпме яшен түкмәгән...
Ялгышканмын сагышларым бетте дип,
Алда икән әле бары да, бетмәгән...

* * *

Мин юлымны, ахры, инде төгәлләдем,
Хисләремне авызлыклап йөгәнләдем.
Әй, Гарифҗан, әллә үзең сизден инде
Гомер көймәң комга килеп терәлгәнен?!

* * *

Гомер инде күчеп бара үткәннәргә,
Күп калмады миннән нидер көткәннәр дә,
Мин дан җырлыйм әле барыбер суынмыйча
Яңа могҗизалар өмет иткәннәргә.

* * *

Рәхмәтлемен язмыш биргән өлешемә,
Кызыкмыйм ятларның алтын-көмешенә,
Шатланам мин, сабый бала кебек,
Үз бакчамда үскән татлы җимешемә.

* * *

Кайчак җилләр түмгәкләргә сөртенә —
Иңрәвеннән хәтта җирләр селкенә,
Алай-болай булмасын дип, хисләремне
Бөтенләй үк җибәрмим мин иркенгә.

* * *

Гомерне мин кичтем ялгыз, яланаяк,
Күңел тарткан якка бардым — юк ла маяк,
Хыял булып алда якты йолдыз янды,
Язмыш булып арттан куды усал таяк.

* * *

Ташулардан алып ташкыннарга
Салды язмыш, әллә артык ашкынганга —
Эзләремне минем табар әле кемдер
Ташкыннардан калган таш-комнарда...

* * *

Яшьлек юлларымда сагалап
Язмыш куйды мине дагалап,
Бу кадәрне юкса тарталмас, дип,
Тормыш юлы бигрәк тайгалак.

* * *

Һәр эшнең дә була ул үз остасы,
Һәр останың була сөйгән остазы...
Оста була, остаз була алмадым мин,
Гафу итегез, егетләр, кыскасы...

* * *

Кыйный икән язмыш, әйдә кыйнасын,
Яшьсез генә җаным үксеп еласын,
Яшьсез елау килешә ул ирләргә дә,
Тик дошманнар гына хәлем тоймасын.

* * *

Селтәгәндә киерелеп чалгымны
Күзләремә затлы чәчәк чалынды —
Чалгым сынды, йөрәк сүнде кинәттән,
Гүя кыйдым үз-үземнең җанымны...

* * *

Мактый-мактый җиде яктан җидегез,
Җиде кат күкләргә мине чөйдегез,
Җиде күктән кабат җиргә төшкән чакта
Тотмадыгыз, сез кайларда идегез?!

* * *

Килә хатлар калалардан, салалардан —
Берәм-берәм дуслар китә аралардан,
Еллар үтә, дуслар китә, уйлар өтә,
Сызлый йөрәк төзәлмәслек яралардан.

* * *

Аяз күктә йолдызларны барладым,
Тиң-тиң итеп берәм-берәм парладым,
Тик бер йолдыз ялгыз калды. Бу дөньяда
Бер мин генә үксез түгел, аңладым...

* * *

Менәр идем бәхет тавы башына —
Шундый хыял белән йөрәк шашына,
Итәгемә бәйләп куйган хәсрәт тавы
Килеп баса шулчак минем каршыма.

* * *

Атна үтә, айлар үтә, еллары —
Сүтелә гел гомеремнең йомгагы,
Бергә-бергә юлга чыккан дусларымның
Арта бара һаман күзен йомганы.

* * *

Күпне югалттым гомеремдә, күпне таптым,
Күпне төзедем дә күпне ваттым,
Югалтулар-табышларым өйрәттеләр мине
Аера белергә асылын харам белән хакның.

* * *

Үткән гомер балкый хәтер көзгесендә —
Күрәм анда гафиллек тә, изгесен дә,
Үкенүләр һәм горурлык хисе итеп
Хәтер сандыгында саклыйм икесен дә.

* * *

Иртән торам да җентекләп кырынам,
Ходай биргән ефәк-бүзгә төренәм,
Кунак көтмим һич кенә дә, шулай иткәч
Үз-үземә матуррак күренәм.

* * *

Бала килеш кидек тормыш камытларын,
Кара инде бу хәтернең онытмавын —
Искә төште елый-елый кул канатып
Чиләнгәннәр бәйли алмый камыт бавын.

* * *

Сорамады, ныгыдымы билең, диеп,
Салды тормыш, синең өлеш, энем, диеп,
Туктап калсам, артка типте усал итеп,
Тарталмагач дөньяга ник килдең, диеп.

* * *

Дусларым бар иде берчак минем дә
Бүлешергә бар булганын күңелдә...
Җилләр генә туктый хәзер янымда,
Хәл беләләр — бәлзәм була җаныма.

* * *

Еллар үтте, инде дуслар сирәк,
Дусларымны сагынып өзгәләнә йөрәк,
Бер көн килер, соңгы дустым булып
Елый-елый миңа кабер казыр көрәк...

* * *

Бу тормыштан алдым инде бик күпне —
Әнкәй назын, сөю язын, ай, күкне...
Ә бурычың бу дөньяга, Гарифҗан,
Үлчәүләргә салып кара — аз күкме?!

* * *

Сөртенә кайчак дүрт аяклы ат та —
Нишләргә соң миңа — ике аяклы затка?
Уйлый-уйлый үзем җавап табалмагач,
Сездән җавап көтеп калам шушы хакта.

* * *

Ат өстендә чабам, мин — җайдак,
Атым елгыр, барыр юл тайгак,
Туганчы ук гомер юлларымны
Минем язмыш куйган шул сайлап.

* * *

Оран салмасам да миргә илереп,
Яраттым мин бу тормышны тилереп,
Кире какты ләкин сөюемне, бахыр,
Барлык хыялларым тетек-җимерек.

* * *

Кайчагында килеп ишек шакый да
Шөбһә дәшә, әйдә, диеп, бакыйга,
Шикләнәм, тик җылы, йомшак урын анда
Булыр микән минем кебек сакыйга?

* * *

Бетте инде, ахры, телем тутыгып —
Гәпләшкән юк дуслар белән утырып,
Табыныма дусларымны җыймый торып,
Булмас, ахры, бу халәттән котылып...

* * *

Дөнья булгач, була икән башсыз башлар,
Үксеп елый ала икән хәтта ташлар...
И Гарифҗан, бу фәлсәфә-уйларыңны
Вакыт җиткән инде сиңа күптән ташлар.

* * *

Кемнең әле хәле уңай минекеннән —
Лап-лап атлап үтә таптап манекеннар,
Манекеннар дөньясында гомер кичеп
Җанын саклап кала алыр икән кемнәр?!

* * *

Бу дөньяда төрлесе бар — көчлеләр дә,
Ара-тирә очрый минем төслеләр дә.
Чабаталар чоры үтте инде, җаныкаем,
Тик музейда урын әзер шөшлеләргә!

* * *

Һич аңламыйм бу атымны, нишләде,
Тынгы бирми җанга таңда кешнәве,
Нигә шулай өзгәләнә икән ул —
Аны дамы язмыш-елан тешләде...

* * *

Ярдәм сорап тамакларым карлыкты,
Белмәделәр җирдә минем барлыкны,
Мин аңладым, җиһан чиксез, ләкин
Мәрхәмәткә анда урын тарлыкны.

* * *

Безнең язмыш — сабый чактан ярлылык,
Белем алдык шәм вә чыра яндырып,
Якты утлар яктысында бәхетсезләр
Бәхет эзли чатыр чабып каңгырып...

* * *

Заман шундый — мулдан үрчи Шаһгалиләр,
Һәр адымың, һәр гамәлең сагалыйлар...
И Гарифҗан, аптырама бу хәлләргә,
Кара елан арттан килеп чага, диләр.

* * *

Мин бит болай бер гөнаһсыз, кяфер түгел,
Кяферлектән айный алмый бары күңел,
Пакьләр идем дә күңелне кяферлектән,
Намус — тавык, ә гөнаһлар тары түгел.

* * *

Мин күрәсен кеше күрмәс, аңлыйм мин,
Шулай диеп үз-үземне алдыйм мин,
Нинди генә авырлыкка очрасам да,
Өметемне өметемә ялгыйм мин.

* * *

Күп татыдым бу язмышның тукмагын,
Вак тормышның бу көндәлек юк-барын,
Җитте диеп нокта куйдым барысына,
Өстен күреп хәләлемнең уклавын.

* * *

Кабат яшәсәң иде бу гомерне!
Учлап тоттым гүя утлы күмерне —
Бер авызы пешкән сабый кабаттан
Салкын суга да ашкынып үрелми...

* * *

Әллә ничек, гел сабыйга охшаган мин,
Юк-барга да борчылучы пошаман мин,
Бу дөньяда җан әрнетер хәлләр барда
Пошынудан, әрнүләрдән бушамам мин.

* * *

Рәхәт яши бу дөньяда башкисәрләр,
Алтын куллы эшсөярләр, ташкисәрләр,
Ташкисәр дә, башкисәр дә булалмадык —
Туа-тумыштан булганбыз баш исәрләр...

* * *

Кем уйлаган, шундый заман безгә тәтер —
Уйлыйсы юк, компьютерда безнең хәтер,
Хәлең ничек, дип сорыйсың, җаныкаем,
Компьютердан сорап карыйк, нәрсә әйтер?

* * *

Арчаларда, Шәмәрдәндә булганым бар,
Поезд көтеп вокзалларда кунганым бар...
Күргәннәрне-белгәннәрне сөйләшәбез,
Өй түремдә минем бүген кунагым бар!

* * *

Уттан алып суга салды бу тормыш,
Судан алып утка салды бу тормыш,
Утны-суны кичкән батыр булып бүген
Президиумда менә утырмыш!

* * *

Мин шәкерте галиҗәнап Хәйям картның,
Аңа ияреп шәраб эчтем, кальян тарттым,
Ул үстергән робагыйлар бакчасында
Күңелемнең аһларына дәва таптым.

* * *

Мөкиббән булды күңелем һәрчак каләмгә,
Каләм алып чыкты олы галәмгә
Һәм өйрәтте читләшергә явызлыктан,
Этәрде җанны гел изге гамәлгә.

* * *

Ак фатиха алганмындыр Рәсүлемнән —
Иткән мине Әлмәндәрләр нәселеннән,
Күңелләр пакь, хыяллар ак, намусым сак,
Шөкер итеп яши бирәм насыйбымнан.

* * *

Очар биеклеге була һәрбер кошның да —
Менә без дә гомер-тауның башында!
Менгән чакта егылмадык, әй, йөрәк,
Төшкәндә дә сынатмыйк, бик ашкынма.

* * *

— Әй, язмышым, күзгә карап бер әйт әле —
Гомер юлым булды ник бик сикәлтәле?
— Шома юлдан гына атлап йөргәннәрнең
Инде күптән югалганын искәрт әле!

* * *

Укып чыктым гомер дигән дәреслекне
(Кем белми минем китапка хирыслыкны!),
Тик өйрәнә алмады җан вакытында
Аерырга ялган белән дөреслекне...

* * *

Язмыш атым юлда ничә дулады,
Ничә кабат Әҗәл биткә сулады,
Ә шулай да үткән еллар сагындыра —
Артта калган еллар изге, догалы...

* * *

Миңа дигән шәраб инде эчелгән,
Хәсрәт дәрьяларым инде кичелгән...
Тукта, Әҗәл, ашыктырма әйдә, дип,
Күрмисеңме, бер чабатам чишелгән!

* * *

Уйландыра бу гомернең агышлары —
Ни күрмәдем, юкса инде таныш бары,
Кайтаваздай кайтып җанга кадала тик
Бездән алда киткәннәрнең тавышлары...

* * *

Күкрәүләр күкрәгән, яшеннәр уйнаган,
Давыл да зилзилә җаннарны буйлаган,
Зилзилә, давыллар тараткан хисләрем
Коелган алмадай, һаман да җыймаган.

* * *

Эш сөймәсе, карьеристы, ахмагы —
Кемнәр генә арттан килеп какмады,
Сөрлексәм дә сер бирмәдем, егылмадым,
Тәңрем мине ташламады, саклады.

* * *

Бу хыяллар әллә кая ымсындырды,
Очам дигән канатларны мең сындырды,
Хыялларны куып җитә алмасак та,
Яшәү өчен акыл дигән тылсым бирде.

* * *

Алданулар әрнүе бәгырен кыйганда,
Үкенү ачысын җанында тойганда,
Үткән гомерен кабат барлый-барлый,
Җанын пакьли чүп-чарлардан бу бәндә.

* * *

Бу дөньяга туа кеше яшәр өчен,
Бар дөньяга, мин тудым, дип дәшәр өчен,
Сирәкләргә ләкин куәт бирә Аллаһ
Башкаларга якты биреп яшьнәр өчен.

* * *

Һаман әле киләчәккә карый күңел,
Унсигезгә яңа аяк баскан күк ул —
Миңа диеп кенә кояш чыга,
Миңа диеп кенә чәчәк ата бу гөл!

* * *

Һәрнәрсәнең бу галәмдә ише бар...
Галәмнәрне иңләп кайтты кешеләр —
Кеше генә бу галәмдә бердәнбер,
Табылмаган анда безнең ишеләр!

* * *

Яшим диеп туа кеше дөньяга —
Дөнья бит ул һәр туганга өр-яңа,

Йә Ходаем, бер гомергә җитәрлек
Олы бәхет, куанычлар бир аңа!

* * *

Һәр көн саен яшьлек ерагырак,
Хисләр нечкә, күңел елагырак,
Яшәешнең асылы ачыгырак,
Һәр җылы сүз җанга тансыгырак.

* * *

Гадәти көн кай тарафтан баксам да,
Юк кесәмдә искитәрлек акчам да,
Тик күңелемдә шатлык тулы, тантана —
Тәүге гөлем чәчәк аткан бакчамда!

* * *

Үз баласын өзелеп сөя елан да —
Аның өчен ул бер сабый олан ла!
Үзебезнең куеныбызда изрәп үскән
Үз балабыз әйләнмәсен еланга...

* * *

Кирәк түгел үз-үзеңне чикләргә,
Хисләреңне читлекләргә бикләргә,
Тик таптама башкаларның хисен —
Бер сәбәпсез этлек кылмый этләр дә.

* * *

Кемнәр генә гомерендә үр менмәгән,
Бәхет эзләп буй җитмәскә үрелмәгән,
Янәшәдә генә йөргән тыйнак бәхет
Ул чакларда күзгә никтер күренмәгән.

* * *

Унны унга тапкырласаң йөз була...
Язлар үткәч, җәйләр үткәч көз була...
Үз бәясен төшермичә яшәгәннәр
Йөз яшьтә дә кара чәчле, төз була...

* * *

Сузылып ятам зәңгәр күккә багып,
Зәңгәрлеген күреп хәйран калып,
Шушы гүзәллеккә күз дә салмый
Кая болай ашыга икән бу халык?!

* * *

И яшәеш, синең өчен ят кемнәр —
Кимсетелгән, рәнҗетелгән, ятимнәр,
Елмаермы аларга да бер кояш,
Күрерләрме аларны бер хакимнәр?

* * *

Алданасын аңласак та алдан ук,
Калабыз ла бик еш кына алданып,
Берәм-берәм үтә көннәр — үтә гомер
Бер ялганнан бер ялганга ялганып...

* * *

Баш ватасы түгел бүген — компьютер бар,
Гәпләшергә сердәш бетте — компьютерлар,
Заманасы шундый диеп күнегербез,
Тик күнекми өзгәләнеп җан сулкылдар.

* * *

Үзеннән дә бөек була алмый һичкем,
Тик зуррагын дәгъва кыла һәрбер мескен,
Егылып беркөн борынын канаткачтын
Эзли башлый елый-елый, сәбәпче кем?

* * *

Җиргә ныклап басар өчен хәл кергәч,
Кесәләргә азмы-күпме мал кергәч,
Оныта кеше фанилыгын бу дөньяның —
Аңлый бары чәчләренә чал кергәч.

* * *

Беләбез ич, кояшта да таплар бар.
Сүзе белән кояштан да пакьләр бар.
Күңелләре кергә батканнар тик
Таплар эзләп башкаларны таптарлар.

* * *

Ришвәт теге дәү абзыйны нишләткән?
Бер сүзем бар әле шушы нисбәттән —
Йөртсәң дә үземне ертык бишмәттән,
Саклый күр, намусым, мине ришвәттән!

* * *

Сокланалар сиңа карап — ай-һай тыйнак!
Юкса бүген әрсез булу күпкә кыйбат:
Бер күзең сал уңга-сулга, май эчендә
Гомер сөрә анда күпме әрсез гыйбад.

* * *

Хәл дә алмый бер утырып-чүгәләп,
Бары да чаба үтим диеп түргәрәк —
Аңламыйча бу дөньяның түре югын,
Җир шары бит йомгак кебек түгәрәк!

* * *

Күрдем биек-биек тауларны,
Башларында эремәс карларны,
Мәңге эремәс карлардан да салкын

Кемнәрнеңдер бәгырь-җаннары.

* * *

Хирыслыгың көчле булды харамга,
Харам борды юлларыңны яманга,
Гомерне дә тапкансыңдыр харам белән —
Сарыф итмәс идең болай әрәмгә...

* * *

Эшләгәне булыр аның һәрчак этлек,
Йөзендә булыр гел ялган битлек,
Уйларын да, хисләрен дә бикләп тотар
Ялган битлек дигән шушы читлек.

* * *

Карыйсың син горур гына биектән,
Беләм инде, син күпләрне «биеткән»,
Карашыңда күптән сүнгән инде якты
Кешеләрне аера торган киектән.

* * *

Узып киттең алмый гына сәламемне,
Һич аңламый калдым ошбу гамәлеңне,
Чит телләрдән ишетеп белдем сәбәпләрен —
Син нәчәлник икән хәзер. Ярар инде!

* * *

Бөекләрнең тиз ачыла бөеклеге,
Аннан тизрәк көекләрнең көеклеге,
Бөек булырга ымсынган көекләрнең
Үзеннән дә алда йөри гел этлеге.

* * *

Башкаларга әйтер өчен сүзе юк,
Гомер үткән, ләкин артта эзе юк,
Язы үткән, җәе үткән гомеренең,
Әмма җимеш җыяр өчен көзе юк...

* * *

Бу тормышта чыкма алга, калма артка,
Иярмә син коммунистка, демократка,
Кала белсәң гомер буе урталыкта,
Яши белә, дип сөйләрләр синең хакта.

* * *

Алдау-ялган кирәк түгел, аңлашыла,
Тик барыбер ара-тирә алдашыла,
Алдап булмый һич кенә дә көзгеләрдән

Күзләреңә карап торган адашыңа.

* * *

Яшәгәннәр үзаралай эт һәм мәче кебек
Зарланалар, бу тормышлар, ай-һай, әче, диеп,
Язмышына мең рәхмәтле яшәгәннәр
Үзаралай чүкердәшеп пар күгәрчен кебек.

* * *

Урамнарда әллә нинди сүзләр йөри —
Кем чыгара, кем тарата, кемдер аны эзләп йөри,
Койрык таксаң нәкъ мин була икән бу, дип,
Арттан шайтан мыштым гына күзләп йөри...

* * *

Нәфес бора кыйблаңны гел уңга-сулга,
Фәрештәләр фатихалый туры юлга...
Уңга-сулга аз йөрдекме, и Гарифҗан,
Ничәмә-ничә «фәрештә» күрдек шунда!

* * *

Никадәрле биек булса ил агасы,
Шулкадәрле зуррак була күләгәсе —
Күпме «ишәк» хыяллана, ничек кенә
Шул күләгә ышыгына эләгәсе.

* * *

Сабый чактан каптыралар имезлек,
Өйрәтәләр, барыбыз да тигез, дип,
Яши-яши күз ачыла, кемдер ябык,
Ә кемнәрдер әллә ничек симез бик...

* * *

Булдырмасаң хет ыштаның ямарга,
Һичьюгында унга кадәр санарга,
Тырыш, энем, түрәләргә ярарга,
Кирәк булса, табаннарын яларга...

* * *

Бер карасаң, буй җитмәслек Гулливер син,
Ыспай гәүдә... Горур караш... Кул бирмисең.
Якынырак танышкачтын тик аңладым —
Тәкәбберлектән кабарган бер нульдер син!

* * *

Рәсемең чыкты күп кат төсле матбугатта —
Бик рәвешле утырасың акбүз атта,
Атка менеп, җилләр куып гомер итү
Бик килешә икән, туган, синдәй затка.

* * *

Үлән диеп атар идең — кыяксыз,
Хайван диеп атар идең — тояксыз,
Кеше диеп атарга да тел бармый —
Кыланышын җир күтәрми, оятсыз.

* * *

Авызыннан бертуктаусыз сибә борчак,
Үзеннән дә алда йөри симез корсак,
Бар ягы да килеп тора, көлеп тора —
Зур бер түрә булыр бу зат, килсә форсат.

* * *

Абзыйларга мактау сүзен күп сайрадың,
Арттан гына тешлим, диеп теш кайрадың,
Еллар үтте, шулай итеп тешсез калдың —
Юк дәрәҗәң, юк хөрмәтең, юк байлыгың...

* * *

Түрәләрне сүгеп йөри эчтән генә,
Тетәр иде, килми бары көчтән генә,
Тетәр иде, сүтәр иде, нитәр иде —
Тик камчысы үрелгән шул өчтән генә!

* * *

Яшим дисәң үрмәлә син өскә тик,
Юл бирмәүчеләр очраса аска тип...
Тын беткәнче үрмәләдем, әй, туган,
Кичә табиб диагноз куйды — астматик!

* * *

Гомер буе алдый кеше, алдана,
Хәятның шул халәтенә җайлана —
Алдый алса канәгать ул, шатлана,
Алдануын күтәралмый, зарлана...

* * *

Мәкерләрнең җыя-җыя иң явызын
Кемдер кемгә үреп ята пәрәвезен,
Уйламый да, үзе үргән шул пәрәвез
Беркөн килеп аяк-куллап сара үзен!

* * *

Хакыйкать ул сулда түгел, уңда түгел,
Безнең йөрәк туры чабар юрга түгел,
Туры гына үтәр идек гомер юлын,

Язмышларның тезгеннәре кулда түгел...

* * *

Еллар белән үлчәмиләр гомерне —
Халык, ил, дип яна белгән гомерле,
Шул максатны үзенә канат итеп
Кызуында суга белгән тимерне.

* * *

Егет тусын бу дөньяга дөлдөл булып,
Кызлар тусын бу дөньяга сөмбел булып,
Муллык булып басуларда иген уңсын,
Бәхет менсен зәңгәр күккә былбыл булып...

* * *

Тауга карап биек таулар булалмыйсың,
Бөркет булып кыяларга куналмыйсың,
Ә шулай да күзләр тауда, күңел — бөркет,
Хыяллар да таудан биек — шуңармы соң?!

* * *

Фидаиләр чатыр чаба көнозын,
Кешелеккә бәхет яулый — көн озын!
Ә кемнәрдер каңгырашып гомер буе
Дөнья куя таба алмый үз-үзен...

* * *

Ирләр булып туганбыз без чыдар өчен,
Мәйданнарның уртасына чыгар өчен,
Кирәк булса, ил язмышын иңгә алып
Давыл аударган имән күк сынар өчен.

* * *

Аз кыйнадымыни язмыш безләрне —
Тезләнмәдек аңа карап тезләрне,
Үзгәр, диеп таләп итте заманалар,
Үзгәрмәдек, заман үзе үзгәрде!

* * *

Кемдер туа бу дөньяга хан булып,
Кемдер туа җитмәгәнгә сан булып.
Мин дан җырлыйм җиргә туганнарга
Батыр рухлы нык фидакарь җан булып.

* * *

Яшәешнең бар бер катгый кануны,
Сорамый ул синең-минем тануны,
Таләп итә җитез аттай чабуны,
Пыскып түгел, ялкынланып януны...

* * *

Йөрәк тибә, һич типмәгән мәле юк,
Йөрәк булгач, аның типми хәле юк,
Йөрәгеңнең тибешеннән калыша күрмә —
Андыйларга шифа-дәва әле юк.

* * *

Шималь балкышына тиң ул яшь вакыт —
Очып китә түмен алганчы татып,
Яшь гомернең һәр минуты саф алтын —
Нидер көтеп кала күрмә син ятып.

* * *

Эзләмичә генә бәхет табылмый ул
(Очкын булмаса, ялкыннар кабынмый ул),
Бәхет эзләп юлга чыккан фидаиләр
Авыр юлда тик бер генә абынмый ул.

* * *

Диңгезләрдә биегрәк дулкыннар,
Биек тауда тирәнрәк упкыннар —
Түбән җаннар ил кайгысын аңлый алмас,
Олы җаннар гына әрнеп сулкылдар...

* * *

Фани дөньяда мин мәңге тормамын,
Бакыйлыкка һич тә дәгъва кылмамын,
Мең рәхмәтле үземә караганда
Гомерлерәк булса җирдә кылганым.

* * *

Җиңел димә тормыш буйлап атлауны —
Тормыш итү җиңел түгел, катлаулы,
Кеше булып калу өчен гомер буе
Хәят сорый пакь намусың саклауны.

* * *

Аерып буламы язларны көзләрдән —
Тик табигать кенә бераз үзгәргән...
Безнең эзләр буйлап кемнәр килә
Ашкынулы язлар эзләп көзләрдән?!

* * *

Бер тырыш кырмыска
Булдым мин тормышта,
Тик эшем кечкенә —
Гомерләр бик кыска...

* * *

Бу хәятның аптырыйм хикмәтенә —
Яшим димә үзеңчә ипләп кенә,
Сизми дә калырсың янәшәңнән
Бәхетең узып киткәнен читләп кенә.

* * *

Кара эзләгәнгә дөнья караңгы
(Гел кашысаң, тирәнәйтер яраңны!),
Чор караңгы, дип зар сөйләп йөрмә син,
Эзлә аны яктыртырлык чараңны!

* * *

Һәрнәрсәгә әрнеп торган — йөрәк ул,
Ярдәм итәм, дияр идең, ерак ул —
Кирәк чакта йөрәгенә ярдәм итә
Ала торган ирләр җирдә сирәк ул...

* * *

Уйламыйча иярәбез юк-барга,
Шул юк-барлар сала башны утларга,
Юк-бар белән кайнар утлар арасында
Ир башына язган гомер итәргә.

* * *

Чын егетне әллә кайдан танып була —
Әйткән сүзе аткан уктай анык була,
Ат иярләп мәйдан тоту галәмәте —
Аяклары бераз гына камыт була...

* * *

Чын егетнең хыяллары — күкләрдә,
Шул хыяллар зур эшләргә күтәрә,
Хыялына канат куя алмаганнар
Бар гомерен тиреслектә үткәрә.

* * *

Очкан кошларга карыйм да сокланам,
Канатсыз булып туганга уфтанам,
Ярый әле хыялларым ак канатлы —
Шул турыда уйланам да тын калам.

* * *

Безнең уйлар һәрвакытта фәлсәфәле,
Җаннар һәрчак якты гамьле, вәсвәсәле,
Уе-гаме якты, җылы булган халык
Ялалардан, яралардан үлмәс әле!

* * *

«Тарихларда без әсәрле, эзлебез» —
Кайта-кайта шул эзләрне эзлибез,
Башка сугып аңсыз итә көн дә Мәскәү,
Тик өметне әле һаман өзмибез...

* * *

Килә минем богаулардан ычкынасым,
«Мин азат!» дип бар дөньяга кычкырасым,
Йә Ходаем, Син яралткан бу дөньяның
Нигә шулай үлчәмнәре өч кенә соң?!

* * *

Бу Иделкәй мәңге шулай ага торыр,
Дулкыннары ярларына кага торыр,
Мең газапны кичеп исән калган халкым
Иделгә тиң хыялларда яна торыр...

* * *

Татар булып туганыма сөенәм —
Үз телемә, үз моңыма сыенам,
Иртә-кичен ялварам мин Аллаһтан,
Аерма, дип, шушы татлы сыемнан.

* * *

Тарихчылар үткәннәрне теркиләр —
Елъязманың иң башында төркиләр!
Кемнәргәдер һич ошамый шул хакыйкать,
Көнләшәләр, ахры, бездән, өркиләр.

* * *

Мин татар, дип күкрәк какмадым,
Үз халкымның данын сатмадым,
Әткәйләрдән алган мирас итеп
Татарлыкны җанда сакладым.

* * *

Нык авышкан Сөембикә манарасы —
Ул халкымның әрнеп торган җан ярасы,
Татарлыгын искәртер гел һәр татарга,
Ава калса хәтта аның хәрабәсе...

* * *

Иңләп-айкап җирне күпме юл үттем —
Кая барсам, аһ-зарларга юлыктым,
Җаным белән аңлыйм хәзер, халык өчен
Иң соң газап икәнлеген коллыкның.

* * *

Бишенче гасыр яшибез коллыкта,
Калган балык кебек сусыз комлыкта,
Буыннарны алыштыра буыннар —
Үлмәгән дә, яшәү дә юк чынлыкта...

* * *

Җилләр узды Идел өстен сукалап,
Дулкыннарны уңга-сулга суккалап,
Иделдәге дулкыннарга кушылып
Йөрәккәем куйды әрнеп-сулкылдап.

* * *

Нинди гамьнәр яши синең калебеңдә,
Калыпланган җаның нәрсә калыбында,
Яшь чыгамы күзләреңнән мөлдерәшеп,
Милли моңнар күңелеңә кагылганда?

* * *

Монда булган тәкъдир безгә каккан казык,
Монда булган безнең җыяр азык —
Язмышлардан узмышлар юк, туганкай,
Шушы җиргә исемебезне әйдә языйк!

* * *

Күп тарихның ачылмаган серләре,
Күп әле аның юасы керләре,
Ни аяныч, кими бара көн дә саен
Халкымның моңа сәләтле ирләре...

* * *

Сагына татар моңлы шагыйрь Такташын,
Ярата сөю җырчысы Гаташын...
И Гарифҗан, инде нәрсә сөйлисең,
Бу урында синең бар ни катнашың?!

* * *

Азмыни соң бу татарның Бакыйлары,
Сәйдәшләре, Туфаннары, Нәкыйләре...
Ә шулай да, бер уйласаң, күбрәк бугай
Кәеф-сафа корып яшәр сакыйлары.

* * *

Яуга чыкса җиңелү белмәс һич татар,
Тынычта да тынгы белмәс, эш катар,
Тик нигә соң килешалмый, бүлешалмый
Бер урынга җыелышса өч татар?!

* * *

Татар бит ул бөек халык — сибелгән,
Бөтен дөнья татар белән чигелгән,
Тик дәвалап булмый аны һич кенә
Татарлыгын оныта торган чиреннән.

* * *

Күп татарга кирәк инде бүген тылмач —
«Хәерле көн!» дип әйталмый иртән торгач,
«Татарга тылмач кирәкми» дигәннәрен
Сызмый булмас инде телдән болай булгач...

* * *

«Ә» дигәнгә ул елмаеп «ә» диде,
«Җә» дигәнгә башын иеп «җә» диде,
Шундый була торгандыр шул, күрәсең,
Бу татарның бүгенге көн җәдиде.

* * *

Белмәсә халык үзенең үткәнен,
Сизми калыр афәт килеп җиткәнен —
Күпме кавем төшеп калган тарихтан,
Абайламый үз-үзенең беткәнен.

* * *

Үз халкыннан аерылса әгәр кеше,
Алга бармас аның кылган һичбер эше,
Харап булыр ул карчыга тырнагында
Төркеменнән аерылган аккош ише.

* * *

Нәселемнең белмим тулы шәҗәрәсен,
Ерак бабамнарның титул-дәрәҗәсен,
Тик хәтерлим тәүге тапкыр күккә баккан
Туган йортның карындыклы тәрәзәсен.

* * *

Дөнья гиздем, күрдем аның күп кыйтгасын,
Авыз иттем күп халыкның аш-боткасын,
Бу дөньяда туган җирдән ямьлерәк җир,
Әнкәй коймагыннан тәмле аш юк ла соң!

* * *

Авылым каршындагы үрләргә мин
Сабый чакта күпме үрмәләдем —
Шушы үрләр өйрәттеләр миңа
Тормыш үрләренә менү сүрәләрен.

* * *

Балачакка кайтып киләм көн дә бер,
Балачагым, кыйблам минем синдәдер,
Күңелеңә моңнар кайчан инде, дисез —
Балачактан аерылган көндәдер...

* * *

Әткәй сүзе: ир була бел, намус сатма!
Намус ауда йөргән чакта йөрәк сакта.
Сорый кебек әткәй көн дә күзгә карап,
Егет була алдыңмы, дип, кирәк чакта.

* * *

Атлап чыккач әткәй йорты бусагасын,
Тормыш дигән дәрья буйлап юл саласың,
Үзең салган юлның тайгак булганына
Олыгайгач үкенүдән ни файда соң?

* * *

Урбар суларында үскән талдан ишеп
Ясый иде әткәй шундый моңлы бишек,
Моңлы бишекләрдә үскәч тирбәлешеп,
Безнең җаннар гамьсез булып калсын ничек?!

* * *

Иңгә-буйга җирне күпме урадым —
Сахарасын күрдем, Дунай, Уралын,
Кая барсам, күңелем ымсындырып
Чакырып торды туган авылым Урбарым.

* * *

И кадерле туган авылым Урбарым,
Синдә туды кызларым һәм улларым,
Син китмисең күңелемнең түреннән,
Кая гына юнәлсә дә юлларым...

* * *

Җилләр иссе чәчем сыйпап талгын гына,
Былбыл сайрап күңелемне салды моңга,
Җилләр китте бөтерелеп әллә кая —
Уйга батып ялгыз басып калдым менә.

* * *

Бала күңеле һәрвакытта далада ла,
Бала күңеле һәрвакытта калада,
Сыкрап яши әнкәйләрнең җаны,
Салаларда берьялгызы кала да...

* * *
Кабат-кабат гомер юлын айкый-айкый,
Агымсуда әнкәй ялгыз керләр чайкый,
Йөзләрендә аның серле моңнар уйный,
Күзләрендә сүнмәс якты нурлар балкый.

* * *
Ашкына күңел яшь чакта далаларга,
Колач җәеп йөзә торган дәрьяларга,
Туган туфрак тарта җанын өлкәнәйгәч —
Җирсеп кайта туып үскән карьяларга...

* * *
Иңли-буйлый бу дөньяның киңлеген
Раслый кеше үз-үзенең кемлеген,
Җитә бер көн — өзгәләнеп эзләп кайта
Туган җирдә өзелеп калган кендеген.

* * *
Бәхет эзләп чит җирләргә киткәннәр
Бәхет түгел, анда газап чиккәннәр,
Туган җиргә кабат кайтып егылалса
Елый-елый туган җирне үпкәннәр.

* * *
Әткәйләрнең күңеле изгедер,
Безгә багар өчен көзгедер,
Тап төшерсәк әгәр шул көзгегә,
Әткәйләрнең җаны өзлегер...

* * *
Гомеремдә мин кылыч йөртмәдем кынында,
Мылтык та алмадым кулыма,
Яшә, дип, дөньяда мылтыксыз, кылычсыз
Васыять калдырам кызыма, улыма.

* * *
Сердәшләрем минем инде бетте дисәм,
Җан дусларым — бөдрә каеннарым исән!
Юатырлар алар башкаемнан сыйпап,
Җылы сорап әгәр яннарына килсәм.

* * *
Сагыну хисем җитез ат итеп,
Туган җирем, кайттым сиңа яд итеп,
Чәчәкләрең читкә борылдылар миннән,

Озак кайтмадың, диеп, мине ят итеп.

* * *

Зәңгәр күлдә аккош кагына
Су чәчрәтеп тирә-ягына,
Кавышу юлы булып канатына
Салават күпере сарыла...

* * *

Кызыл диплом кирәк түгел сандугачка,
Болай да шаны югары — сандугач ла!
Үз гаменә чакыра ул дәртләндереп
Ак җаннарны, пакь җаннарны таң тугач та...

* * *

Баш өстендә ике башлы сәмруг кошы,
Йөрәгеңне чукыйм, ди ул тәмуг кошы,
Кайчан гына үтәр икән, бетәр икән
Озак сузылган җан өшеткеч сәмум кышы?

* * *

Нидер көтеп кул сузабыз Мәскәүләргә,
Ышанабыз кайчак әллә нәрсәләргә,
Нидер салыр дип көтәбез уч төбенә —
Үзебезнең кулда икән гәрчә бары да.

* * *

Рәсәй кабат биеклеккә үрли бара,
Дөнья инде аннан кабат шүрли бара,
Шул биеклектән егылып баш ватасын
Абайламый әле һаман, сизми бала...

* * *

Мәңге яшәр империя тумаган,
Бу җәһәттән безнең бәхет булмаган —
Йә терелми, йә таралмый бу Рәсәй,
Нигә икән, сорап яздым Думадан.

* * *

Демократик ил төзибез, дидекме без?
Ни теләсәң, шуны кычкыр, ирекле без!
Тик онытма — булмас сине ишетүче,
Син сораган мәсьәләне эш итүче.

* * *

Күп сикердек уңнан сулга, сулдан — уңга,
Басалмыйбыз әле һаман туры юлга,
Әйтерсең лә Рәсәй дигән бу мәмләкәт
Яңгырдан соң ярдан чыккан коры елга...

* * *

Низагларны хәл итәлми орышлар,
Исәп-сансыз бер-береңне кырышлар.
Аңлаганчы шушы гади хакыйкатьне
Рәтләнмәстер бу Рәсәйдә тормышлар...

* * *

Сөрер өчен изгеләрне, «кулаклар»ны
Мул төзегән Рәсәй төрмә, ГУЛАГларны,
Шулар каны тынгы бирми бәдәненә,
Озакка китте бу дәүләтнең тулгаклары.

* * *

Бу Рәсәйгә кирәк инде алгарыш,
Бу Рәсәйгә кирәк инде яңарыш,
Тик итәктән артка тарта һаман да шул
Сүз болгатып, сүз кайнатып калган эш.

* * *

Изге гамәлләр кылуны тыйдык без,
Күпме изгеләрнең башын кыйдык без,
Ил әйләнде бозыклыклар дәрьясына —
Нәтиҗәдә шундый уңыш җыйдык без.

* * *

Бәхетлеләр бик сирәк шул бу илдә,
Күпме генә тирең түкмә, бөгелмә,
Яулый алмый кеше үзенең хокукларын,
Үтә аның бар гомере дуэльдә.

* * *

Бу җәмгыять гел базарга күчә бара,
Алдан һәрчак доллар тулы кесә бара,
Һәрнәрсәнең бәяләре үсә бара,
Тик... кешенең бәясе гел төшә бара.

* * *

Заманалар бүген болгавыр,
Яшәүләре, ай-һай, бик авыр —
Илең булгач штурвалсыз кораб,
Ярты халкың калгач зимагур...

* * *

Дошман юкта аны уйлап таптык без,
«Дошман» дигән кара ярлык тактык без,
Хәзер инде уңыш җыяр вакыт җитте —
Шул чәчкәннең җимешләрен татыйбыз.

* * *

Җимердек илне, шул хакта яздык акт,
Торгызыйк кабат дип төзедек контракт,
Шуннан бирле бер кадак та кагалмадык —
Еллар уза, бездә һаман антракт...

* * *

Йөз ел корганны бетердек таратып,
Эшлик инде кабат кулны канатып,
Йөз ел үткәч беркөн кабат таратырбыз
Ваучер дигән кәгазьләрне яңартып.

* * *

Күнектек инде базарга, бартерларга,
Куркытмый хәзер Бушлар да, Картерлар да,
Йә Ходаем, үзең сакла, үзең якла
Мочить итәм дигәннәрдән сортирларда.

* * *

Матур булсын, имин булсын ил, диеп,
Тимәсен аңарга давыл-җил, диеп
Үткәргәнбез гомерләрне заяга,
Туймас тамакларга кызыл мал җыеп...

* * *

Көтә торгач килде безгә демократик киңлек,
Һәммәбезгә дәүләт бүлеп бирде милек:
Кемгә завод, рудник бүләк итте,
Ә кемгәдер насыйп булды сыңар миллек.

* * *

Әкиятләрдә алдап йөри Алдарлар,
Чынбарлыкта алдый Чубайс, Гайдарлар,
Алданырга әзер торган халык барда
Кимемәстер бу Рәсәйдә алдарлар.

* * *

Мактанабыз, тормыш әйбәт, ничава, дип,
Юанабыз, тәкъдир кушкач ни чара, дип,
Кысык күзләр читтән карап башын селки,
Газаплана мескен халык, бичара, дип.

* * *

Берәм-берәм еллар үтеп тора —
Өр-яңасы бусагада көтеп тора,
Анысы да үтәр хыялларны таптап,
Искә алырбыз «Эх ул еллар!» диеп мактап.

* * *

Без кабызган утлар якты балкып яна,

Тик башкалар аннан бүген якты ала,
Бу заманның кануннары катгый —
Эшләгәннәр җыелып читтә кала.

* * *

Бу гасырның килеп җиттек ахырына,
Керә тарих кер тимәгән гасырына,
Каннибаллар һәм маньяклар безнең белән —
Керләнмәс ул дип һич тә син шапырынма!

* * *

Атаганнар безне зурлап — халык диеп,
Тоттырганнар лозунглар «Халык — бөек!»,
Шул халыкның баш өстендә шайтан туе —
Хакимдарлар бәйрәм итә җырлап-биеп.

* * *

Сөйләп тора, гүләп тора парламентлар,
Халык хакын кайгырталар — җанга нектар,
Халык хакын кайгырталар бик яратып —
Сүз ашатып, сүз эчертеп, сүз ялатып...

* * *

Адашулар, алдашулар китте безнең зурга,
Җитте вакыт, өр, Исрафил, сурга,
Бу дөньяда адәм көлдергәнче,
Ахирәттә калсак калыйк хурга...

* * *

Мин галим димәс һич белем алганнар,
Акыл сатар һәр чат саен наданнар,
Инеш сасый өстен чүп-чар басканнан,
Дәүләт аксый, «өс»кә менсә наданнар.

* * *

Бюрократлар бюрократны куып тора,
Ни аяныч, яңалары туып тора,
Шул турыда уйланам да, әллә ничек
Йөрәккәем салкын боздай туңып тора...

* * *

Балык чиртми инде хәзер елгаларда,
Менеп чабар өчен бетте юргалар да,
Тик күбәйде бик осталар мөнбәрләрдән,
Яшәү рәхәт, диеп безне юмаларга.

* * *

Әй буталды, актарылды бу заман,
Ил караклары бу көндә узаман,
Ихлас узаманнар сабыр гына
Гомер итә дәрман алып узганнан...

* * *

Аяк бастык менә яңа гасырга —
Үзе болай яңа түгел асылда,
Һаман да шул сүнгән йөзләр, гаҗиз башын
Белми йөргән кая алып качарга.

* * *

Бездән соң да сулар агар, җилләр исәр,
Бу җиһанга туар, яшәр бик күп исәр —
Исәр булып яшәү кирәк бу дәүләттә,
Юкса җәллад дошман диеп башың кисәр.

* * *

Бәрәкәтле ел теләдек Ходайдан,
Мул уңыш үстердек арыш-бодайдан —
Икмәкләргә тагын бәя артыр инде
Игеннәрне җыеп алгач, бер айдан...

* * *

Фатир саен ике катлы тимер ишек,
Шундый заман — кеше эзли тимер ышык,
Тимер ишек артларына сыенышып
Гомер итә безнең халык тилмерешеп.

* * *

Кара шакмак ясап берәү дан алган —
Дөньядагы бөек рәссам саналган,
Кешеләрне алдау өчен күп кирәкми,
Җитә ыштаның булса да ямалган...

* * *

Изге булып уйный һаман Иблисләр,
Фәрештә булып кылана Владимирлар, Ильичлар,
Йөз елына түзде тарих, кая барсын,
Тагын йөз ел дәвам итсә гавам нишләр?!

* * *

Яэҗүҗ-мәэҗүҗ купты бүген җиһанда,
Оят, намус, вөҗдан бетте инсанда,
Үз вакытында үз намусын валютага
Сатылганнар батыр бүген, иң санда...

* * *

Мең кабатлыйк көн дә саен «сөям» диеп,
Мәхәббәткә һәйкәл куйыйк гүзәл, бөек,
Мең кат артыр бу дөньяның гүзәллеге,
Яши белсәк бер-беребезне сөя белеп.

* * *

Серләремне сакладым мин тирәндә —
Сер бирмәдем һәрбер сөям дигәнгә,
Һәр сарылган җилдән җиргә бөгелсә
Имән була алмас иде имән дә...

* * *

Әй Гарифҗан, алтмыш биштә яшең!
Тик... әйтте кичә гүзәл бер сеңелкәшем:
— Ай-һай, абзый, һәрбер сүзең бәлзәм,
Һәр карашың әле синең утлы яшен!

* * *

Әткәй тамак кыра иде алдашканда,
Әнкәй юл күрсәтә иде адашканда,
Беркем хәзер тамак кырмый, сүзне бормый
Һичьюгында хатын белән талашканда...

* * *

Бу яшәеш дигәннәре мәзәк икән,
Аның асылы сөю дигән ләззәт икән,
Шул ләззәтне ахыргача татыр өчен
Бер гомерең ни дисәң дә азрак икән...

* * *

Һәр чибәрнең куенын капшый — җил исәр,
Һәр җилбәзәккә ымсынам — мин исәр,
Исәр җилләр, исәр күзләр исән чакта
Мәхәббәт гөлләре сулмас, гел үсәр!

* * *

Яздым әле робагыйлар — йөз дә берне,
Багышладым арасында сезгә берне,
Калганында кара кашлар, нечкә билләр —
Шулар өзә җитмеш яшьтә үзәгемне.

* * *

Син әйтәсең, бу гомернең чиге бар!
Күңелемнең тик бер генә шиге бар —
Минем йөрәк мәңгелектер, гүзәлләрне
Күргәч аттай ярсый торган «чире» бар.

* * *

Сөйгән яр затлы бер гөл ул — беләбез,
Без үстергән гөл түгел ул — беләбез,
Кача-поса шул бакчага керәбез,
Шул иң затлы гөлчәчәкне өзәбез...

* * *

Әллә соң без төшеп калган егетме,
Егетләрнең егете без — элитный,
Чибәр кызга караганда тик менә
Баш әйләнә, тел бәйләнә — ни җитми?!

* * *

Әйләндермәсен башыңны чибәрләр —
Көн килер дә, алар беркөн шиңәрләр...
И Гарифҗан, моны кемгә сөйлисең,
Мәхәббәттә ярдәм итми шигарьләр!

* * *

Иңен куйды һәрчак батырлар,
«Җимен» бирде сөйгән матурлар.
Егет гомере — юлда, юлдагылар әле
Мин күргәнне күп кат татырлар...

* * *

Язлар җитте, көн җылынды, карлар эреде,
Җир куенына бәрәкәтле орлык керде,
Яшь кызларның күңеленә ал гөлләрдән
Тәүге сөю мең газаплы хыял үрде...

* * *

Үсмер чакта гашыйк идек апаларга
(Керсез күңел тарта бит ул хаталарга),
Хәзер инде җирсендерә күңелләрне
Сеңелкәшләр кунак булып кайталар да...

* * *

Яшь чагында бу абзаң да кенәз иде —
Урамнарны шаулатмаган көн аз иде...
Кәләпүшне киеп башка, басып ташка
Тәкъва булып яшәп карыйк бераз инде.

* * *

— Без яшь чакта сафрак иде сөюләр,
Кайнаррак иде янып көюләр...
— Мәхәббәтнең суынып сулганы юк,
Үзең, ахры, суынгансың, и юләр!

* * *

Абау, җаным, танып алдым — шул капка!

Келт иттереп уйлап куйдым шул хакта —
Кочагымнан елдам гына ычкынып
Үптермичә кереп качтың шул чакта...

* * *

Безнең күзләр булды һаман чибәрләрдә,
Көндәшләр дә «менгәләде» чигәләргә...
Шул турыда хатирәләр сөйләп йөрим
Күрше-тирәдәге чибәр җиңгәләргә.

* * *

Гашыйк булабыз еш кына бер караштан,
Күпме татлы караш балкый һәр тарафтан...
Шундый өмет-уйлар белән исәрләнеп
Чыгып киләм чәч ясатып чәчтараштан.

* * *

Үткәннәрдән мут карашлар карап тора,
Җәрәхәтле җаным шуннан канап тора,
Әле дә ярый төнне таңнар алыштыра —
Таңнар килеп сагышларны тараттыра.

* * *

Нәфес дигән Газазилне кыйный-кыйный
Үтеп киткән бу гомерләр назлар тоймый,
Юкса назлар үткәннәрдә аз булганмы?
Азгын нәфес күпме сыйласаң да туймый...

* * *

Бу дөньяның була, имеш, өч почмагы —
Шәраб эчмәк, хәсрәт кичмәк, хур кочмагы...
И Гарифҗан, барысын да кичтең кебек,
Ни көтәсең бу дөньядан инде тагы?!

* * *

Бу йөрәгем шуны сизеп азган икән —
Моңсуланып йөри торгач язлар җиткән!
Азгынлыгым күпкә микән, азга микән,
Бу язларда безгә ниләр язган икән?

* * *

Салды башны бу мәхәббәт сәмумнарга,
Буйсындырды әллә нинди кануннарга —
Баш күтәреп карарга да шүрлим хәзер
Нечкә билле, кара кашлы ханымнарга...

* * *

Мәхәббәттә безнең хокук тигез булсын —
Мәхәббәт кодексына шул нигез булсын,
Сөйгәннәргә сайлап алу мөмкинлеге

Ике түгел, һичьюгында сигез булсын!

* * *

Син дә мине яраткансың, акыллым,
Мин дә синең кочагыңа атылдым,
Синең — ирең, минем хатын булмаса, һай...
Тфү-тфү, мин әйтмәдем, хатыным!

* * *

Үтә гүзәлләр күзенә бакма икән,
Мут күзләрнең төпләренә батма икән,
Чибәр ярлар сөям диеп, язмышыңны
Касә кебек челпәрәмә ватма икән...

* * *

Шушы сорау борчый күптән җәмәгатьне:
Сөю нәрсә — сәнгатьме ул, сәнәгатьме?
Сөю-сәгадәт эшенең торышыннан
Бүгенге безнең хөкүмәт канәгатьме?

* * *

Кемнәр генә «сөям», диеп сөйләнмәгән,
Үзен алдап, сөймәгәнгә өйләнмәгән...
Ни дисәң дә бу мәхәббәт мәсьәләсе
Уголовный кодекста көйләнмәгән.

* * *

Мәхәббәттә гаепләме алдаганнар,
Әллә күбрәк гаепләме алданганнар?
Газет аша миңа җавап бирегезче,
Яши-яши шул сорауны аңлаганнар!

* * *

Алтын орлык шытып чыгар сөргән җирдән,
Күңелләрдә хис уяныр сөрән-җырдан,
Ир башына җитә инде мут хатыннар,
Хатын башы җәфа чигә сүрән ирдән.

* * *

Мәхәббәттә кирәкмени үлчәү-бизмән —
Мәхәббәттә җиңү яулый иң күп түзгән...
Болай гына акыл сатып утырам ла,
Безнең инде ара өзгән, күңел бизгән...

* * *

Без яшь чакта шактый гына мут та идек,
Кыз-кыркыннар арасында хутлы идек,
Тик шуларның берсе — гомер юлдашым
Кырт кистерә, сөйләмәче юкны, диеп.

* * *

Үз-үземә катгый итеп бирдем нәзер —
Чит-ятларга күз дә салмыйм инде хәзер,
Юктан гына торган икән барысы да —
Хатын алдында нык үсте минем кадер.

* * *

Ни булса да гел яхшыга юрадым,
Гел изгегә таба булды юлларым,
Бу дөньяда үз-үземне күп чикләдем,
Бакый йортта күбрәк бирсен хурларын.

* * *

Чыккан булсам да чигеннән кырыкның,
Картаюдан һич кенә дә курыкмыйм —
Биш мәртәбә гашыйк булам көненә
Юлларымда чибәр кызлар күреп мин.

* * *

Тукта инде, ни эшлисең, юләр, дисең,
Күрсә әгәр бездән кеше көләр, дисең,
Ә мин уйлыйм, ул көлгәннәр сөю-назсыз
Үткән көннәрнең әҗерен түләрме соң?!

* * *

Җир селкетер ат йөрәкле егетең
Җиңә алмый кайчак хәләл җефетен,
Мәхәббәтнең көче зуррак егетлектән —
Егетне дә калдыра ул җебетеп!

* * *

Ни дип кенә җавап бирим инде сиңа,
Мин түгел бит әле сиңа Ибне Сина —
Бер адашсаң кереп сөю бакчасына,
Чыгам димә хәтта атаң акчасына!

* * *

Күрәсең, мин төзәлмәс бер фасикъ-тыр,
Фасикъларга шундый язмыш насыйптыр:
Бу дөньяда ничә гүзәл бар икән —
Мин аларның барысына да гашыйктыр...

* * *

Кеше китә — җырланмаган җырлар кала,
Бөдрә таллар, яңа яуган карлар кала,
Әйтелмәгән сүзләр кала, зарлар кала,
Без сөймәгән, без кочмаган ярлар кала...

* * *

Минем күңел бер җилбәзәк, чуар инде,

Язлар җитә, тагын акылың җуяр инде...
Адәм белән Хаваны да ярлыкаган,
Бу гөнаһны гына Тәңре юар инде...

* * *

Картлык басып тора дисең өч адымда,
Уйламыйм мин ул турыда пычагым да,
Өч гүзәлне җылытып чыгарырлык
Кайнар ут бар әле минем кочагымда!

* * *

Күпме йөрдем ничек сүзләр катыйм, дип,
Уйламыйм да, дәшәм хәзер «хатын!» дип,
Ашың пешкән, чәең кайнап чыкканмы,
Арып-талып мин бит эштән кайттым, дип.

* * *

Ир-егетнең бар белгәне кара күзле кызлар икән,
Үлгәндә дә җаным кызлар диеп сызлар микән,
Еллар үтеп, синең кызны озатып килсә минем малай,
Бу казыгыз аңарга да усал итеп ыслар микән?..

* * *

Доллар бүген җәмгыятьнең байрагы,
Хатыннарга кирәк ирнең баерагы —
Уңга таба, сулга таба бора торган,
Акыл ягы бераз гына саерагы...

* * *

Җырлар язып зур шагыйрьләр акын була...
Сөя-сөя сөйгән ярлар хатын була...
Хатын булгач, сөйгән ярлар ник бозыла?
Бу сорауның җавапларын шайтан белә!

* * *

Мин белмәгән күпме сер бар — беләсем килә,
Мин күрмәгән күпме җир бар — күрәсем килә,
Оҗмах дигән сүз ишетсәм әллә нишлим,
Хур кызлары көтә мине — үләсем килә.

* * *

Азмы сөю фронтында туралганнар,
Сөю ялкынына кереп уралганнар
Һәм... шул фронт кырларында көтмәгәндә
Кинәт кенә хат-хәбәрсез югалганнар.

* * *

Җиккән атлар безнең хәзер атом гына,
Үзаралый аңлашабыз «матом» гына,
Өйгә кайткач, кадерлем, дип, җанашым, дип

Кәеф бозып куя кайчак хатын гына.

* * *

Үтим диеп хатынымның әмерен
Ташладым мин тәмәкесен, хәмерен,
Өченчесен һич кенә дә ташлый алмый
Өзгәләнә бу бичара бәгырем.

* * *

Хатын-кызның, беләм, яшен сорамыйлар,
Җитмештә дә унсигезгә тора, диләр,
Җитмеш ничә яшьлек зиһене белән
Унсигездәгечә тозак кора, диләр...

* * *

Кемнәр генә яши икән сагынмыйча,
Сөйми калганнар алдында табынмыйча...
Хатирәләр җылыта җанны тилмерткәндә
Учактагы чи утыннар кабынмыйча.

* * *

Ишемия, диләр, инсульт, инфарктлар...
Уйланам да, оча минем котлар,
Җәннәт ишеген ачып кергән чакта
Кайсы җария мине кочып котлар?!

* * *

Бер уйласаң, бу мәхәббәт харап инде
(Мәхәббәт бакчасында без карак инде!)...
Тфү-тфү, үткәннәргә-сүткәннәргә
Абзагыздан өч мәртәбә талак инде.

* * *

Ике яры кысып тора инешне —
Һәр инешкә ике яры тиешле,
Безнең кебек егетләргә тик бер яр —
Бу гаделлек түгел инде, кәнишне!

* * *

Инде язлар җитә, диеп көтәм мин дә —
Бу көннәрдә тынып тора ютәлем дә,
Чибәр кызлар карап китсә бер борылып,
Пычагыма, кирәк түгел витамин да!

* * *

Оныкларым менде инде тезләремә,
Кереп барам гомеремнең көзләренә,
Абыстайлар түгел әле, асыл затлар
Күбрәк күренә һаман минем күзләремә...

* * *

Кемгә сөйлим күңелдәге бу аһ-зарым,
Сыкрап калды, әрнеп калды мескен җаным,
Миңа таба күз дә салмый узып китте,
Әллә күзсез микән соң бу чибәр ханым?!

* * *

Әҗәл диеп ник шүрлисең, пычагым,
Хур кызлары көтә җәеп кочагын,
Гомер буе мәхәббәткә туялмадың —
Анда баргач бер кинәнер ач җаның!

* * *

Әй язмышлар, безне кая ашыктыра?
Юл читендә күпме афәт качып тора:
Юлбасарлар ике кулын кашып тора,
Фахишәләр «мал-мөлкәтен» ачып тора...

* * *

Сөю килә бәгыреңне телә-телә,
Синең мәҗнүнлегең күреп көлә-көлә,
Мәҗнүн булып кылануның үз сере бар —
Анысын инде кыланучы үзе белә...

* * *

— Сәламемне ник алмадың мин кергәндә,
Син, туганкай, әле алай эреләнмә!
— Хатын йоклый, әкрен сөйләш, бик шаулама,
Кергәнеңне күрми калдым кер элгәндә!

* * *

Санама ла мине болай җүләргә син,
Минем күзгә кара төтен җибәрмә син —
Нигә әле әйләнәсең-тулганасың
Кичә минем күзем төшкән чибәргә син!

* * *

Калды микән уйлар — без уйламаган,
Калды микән утлар — без уйнамаган...
Кабатлыйсы мәллә, туган, бу гомерне,
Кала күпме гүзәл без туйламаган...

* * *

Мин кызларга гашыйк инде, беләсең,
Нигә әле мыек астан көләсең?
Көл-көл, әйдә, белеп торам, әй туган,
Синең дә бар шул утларга керәсең!..

* * *

Күңел һаман урап кайта үткәннәргә —

Оялып кына тәүге кабат үпкәннәргә...
Кемнәр үбешеп утыра икән бүген таңда
Капка төбендәге таныш бүкәннәрдә?

* * *

Һәркемнең дә табыла үз чибәре —
Үзенә дип кенә пешкән җиләге,
Иң чибәрләр ләкин читтә ялгыз кала,
Әллә булмый үзләренә тиңнәре?!

* * *

— Бәбкәләрне кара, балам, тилгән йөри,
Безнең турыга юкка түгел, килгән юри,
Апаеңны сиздермичә урлап качкан
Үткен күзле кара мыек җизнәң кеби...

* * *

Килиманджаро сыртларын кочсаң иде...
Җылы маржалар куенын ачсаң иде...
Барына да ирештем дип хыялларның,
Карлыгачтай шашып күктә очсаң иде...

* * *

Бакчаларда алма күп лә — пешмәгән,
Тулып пешеп җиргә өзелеп төшмәгән,
Ята бары ялгыз гына бер алма —
Өлгергәнче кемдер өзеп тешләгән...

* * *

Һәр гүзәлне күреп җан аттым —
Ничә кабат җаным канаттым.
Зарлануым түгел, болай гына,
Бу дөньяга килмәм кабат мин...

* * *

Яшәү дәртен сездән алдым, гүзәлләр,
Сезне мактап яздым күпме газәлләр!
Гүзәлләр дә, газәлләр дә кала икән,
Муеныңнан кочып алса Әҗәлләр...

* * *

Татый алсаң чын сөюне дөньялыкта
Битәрләнмә яшәдем дип җирдә юкка,
Аллаһ юлың тәгаенләр тик җәннәткә —
Сөю утыннан кайнар ут юк тәмугта.

* * *

Күмгән чакта салкын туфрак җәсәдеңне,
Биргән чакта ахирәттә хисабыңны,
Ни әйтерсең дөньялыкта сөелмичә

Суындырсаң изге сөю хисләреңне?

* * *

Таулар — биек, түбәсендә кар бетмәс,
Күңел — диңгез, төпләрендә зар бетмәс,
Үз тиңеңне эзлә, йөрәк, адашма,
Чибәрләр күп, ымсындырган яр бетмәс...

* * *

Кемдер таба яшәү ямен шәрабтан,
Кемнеңдер күңеле була шәрәфтән,
Минем күңелем башка төрле, сабыйларча
Дулкынлана һәрбер серле караштан.

* * *

Гүзәлләрнең белә идек сөйдергәнен,
Тик белмәдек утка салып көйдергәнен,
Уттан — суга, судан утка салып,
Горур башны Мәҗнүн кебек идергәнен...

* * *

Сөю утларында без дә азмы яндык —
Күңел тулы хатирәләр, хәтер — сандык,
Күңел көн дә бер актара хәтер төбен,
Шул утларда, әйдә, кабат бер кат ян, дип.

* * *

Үксез тоям гел үземне чит җирдә мин —
Һавасы да җанга ятмый чит җирләрнең,
Карашлары хур кызыдай булганда да
Сулышы җанга шифа бирми һәр чибәрнең.

* * *

Күзләреңдә уйный синең серле балкыш,
Иңнәреңдә ап-ак шәлең — син бер аккош...
Үткәннәргә кайтып сине уйлаганда,
Күз алдымда балкый шушы рәсем-нәкыш.

* * *

Килгәнбез без бу дөньяга яратырга,
Бердән-беребезне сөеп җан атарга,
Сөю дигән иң борынгы изге хисне
Үзебезчә савыктырып яңартырга...

* * *

Төшләреңә әле синең керермен мин,
Төшләремдә һаман сине күрермен мин,
Үткәннәргә кабат-кабат кайтырмын да
Мең кат үлеп әле мең кат терелермен...

* * *

Итәгеңә кунган кызыл тигәнәк,
Түшләреңә — шаян чуар күбәләк,
Сине күреп хәйран калдым, җаныкаем,
Бу дөнья бит шундый камил, түгәрәк!

* * *

Тәүге сөю кемгә килә җилләр булып,
Кемгә килә туфан булып, силләр булып,
Җил булса да, сил булса да, каршы йөгер,
Читтә генә йоклап калма юләр булып...

* * *

Мең рәхмәтле күңелем сиңа әле дә,
Кердең барыбер бераз минем хәлемә —
Янәшәмнән үтеп киткән чагында
Кулым тиде синең йомшак шәлеңә...

* * *

Гашыйкларның күңелләре гел аһ булыр,
Шул аһларын гаеп итсәк гөнаһ булыр,
Алтын сарайларда ялгыз интеккәннәр
Кавышсалар, гади шалаш оҗмах булыр.

* * *

Мәхәббәтнең кануннары катгый анык,
Ләззәтләре җир өстендә ятмый анык,
Татыйм дисәң мәхәббәтнең бар ләззәтен,
Таң чыгыдай керсез булсын гашыйк җаның!

* * *

Бу мәхәббәт килә нигә кинәт кенә,
Килсен иде җайлап, барын көйләп кенә,
Җайлап-көйләп килеп, чияләйләп
Китсен иде язмышларны төйнәп кенә...

* * *

Сөю дигәннәре серле тозак икән,
Бер эләксәң, ычкынуы озак икән —
Гомер буе кала алсаң шул тозакта,
Ил алдында дәрәҗәң зур, йөз ак икән!

* * *

«Сөям», диеп кемнәр генә азмаган,
Аны данлап кемнәр җырлар язмаган,
Тик берсе дә сөю дигән изге хисне
Гөнаһ диеп исемләргә базмаган.

* * *

Авыр була аерылып киткәннәргә,
Тагы да авыр өзгәләнеп көткәннәргә,
Тик барыбер килә бит ул кавышу көне
Өзгәләнеп көткән, сабыр иткәннәргә.

* * *

Сүрәннәргә җылы көннәр бирсен Ходай,
Сөйгәннәргә айлы төннәр бирсен Ходай,
Мәхәббәтен таба алмый йөргәннәрнең
Хыялларын бәхет итеп үрсен Ходай...

* * *

Әле генә сәгать сукты уникене,
Тынды йөрәк — синекеме, минекеме?
Ике йөрәк бердәй булып тибә икән,
Туктаулары-тынулары бик икеле!

* * *

Әйткән сүзнең артларыннан эзләмә,
Югалткан ярларны кабат күзләмә,
Сүзнең кайтыр кайтавазы, ярның — назы,
Өметеңне бөтенләй үк өзмә дә.

* * *

Мин дөньяга килдем сөю иленнән —
Өзелеп төшеп назлы сөю гөленнән,
Бабайларың шиңдермәгән шушы гөлне
Сусыз итмә, дип үтенәм киленнән...

* * *

Кем үлчәгән йөрәктәге сагышларны —
Йөрәкләргә сыймый торган сагыш бармы?!
Бер җавапсыз сөю, көю, өзгәләнү —
Бу сагышлар, туган, сиңа таныш лармы?!

* * *

Зарланасың, кемнәр тыңлар зарыңны,
Белмәсләр дә җирдә синең барыңны,
Җан җылысын әллә кайдан эзләмә —
Кочакла да йокла сөйгән ярыңны...

* * *

Алан тулы җиләк кенә — төрледән,
Иң җетесе — кызарып пешкән бөрлегән.
Бөрлегәннәр дә күренми күземә —
Алларымда син торасың, бер генәм!

* * *

Сөю утларында яндым мең кабат,
«Сөям», диеп җырлар яздым мең табак,
Түшләреңә күбәләктәй кунар идем,
Йә Ходаем, иңнәремә бир канат!

* * *

Кемнәргәдер кирәк Париж, Токиолар,
Бездәй тупас түгел, имеш, тонкий алар,
Мин яз көтәм, туган авыл болыныннан
Сиңа үреп кайту өчен такыялар...

* * *

Күкне ярып Җиргә йолдыз атылды,
Әйтерсең лә күк гөмбәзе ватылды —
Ике гашыйк бер-берсенең күкрәгендә
Сөю дигән изге гамьне татыды...

* * *

Мин дөньяда иң тиңдәшсез бәхтияр,
«Сөям», диеп миңа бүген дәште яр,
Яшьлекнең шул сәгадәтле мизгелендә
«Афәрин!» дип фәрештәләр дәштеләр.

* * *

Кеше туа бу дөньяга сөяр өчен,
Сөйгәненә изге сүзләр сөйләр өчен,
Сөйгән яры йөрәгенә юллар ярып,
Аның назлы күкрәгенә сеңәр өчен...

* * *

Без бу җиргә сөяр өчен туганбыз —
Әллә Фәрһад-Шириннарга туган без,
Бәхетебезгә насыйп ярны табыйм, диеп,
Шаша-шаша күпме дөнья куганбыз!

* * *

Былбыл булсам, сөям, диеп җырлар идем,
Чишмә булсам, яратам, дип чыңлар идем,
Әгәр дә син былбыл булсаң, чишмә булсаң,
Гомер буе сине генә тыңлар идем.

* * *

Сүнмәгән бит әле соңгы өметләр —
«Сөям», диеп әйтәләбез, егетләр,

Сөю хисен югалтмаган йөрәкләрнең
Туктамыйча тибәсенә өмет бар!

* * *
Язмышымны бирдем синең кулыңа,
Адаштырмассың дип гомер юлымда,
Шуңа күрә нык минем һәр адымым,
Уйламыйм да ару-талу турында...

* * *
Әверелеп таңда бер чык бөртегенә,
Кунармын да бер гөлеңнең керфегенә,
Тәүге кояш нурларында эрермен мин,
Тик күзләрең бары мине күрсен генә!

* * *
Таң йокыңны әле синең алырмын мин,
Башкаеңны сагышларга салырмын мин,
Уйларыңнан чыкмый шулай иртә-кичен
Йөрәгеңә барыбер юллар салырмын мин.

* * *
Моңсулыгы синең күзләреңнең —
Бер җылысы гомер көзләремнең,
Синең күзләр җанны җылытканда,
Яшәүләрдән өмет өзмәмен мин.

* * *
Безнең сөю инде кат-кат сыналды,
Давылларда һәм җилләрдә кыйналды,
Кыйнауларны-сынауларны сынмый үтеп,
Гомерлеккә җаннар җанга төйнәлде.

* * *
Ялгыш кына бактым кинәт зәңгәр күзгә,
Җан-фәрманга чапты күңел унсигезгә,
Шунда калган кояш нуры бөркеп торган
Зәңгәр күктәй зәңгәр күзле кызны эзләп...

* * *
Нинди җепләр тоташтырды әле безне —
Хыялларны, җаныбызны, тәнебезне,
Акыл җитмәс, сүзләр көчсез аңлатырга,
Белсә бары Ходай белер хәлебезне!

* * *

Күңелемнең йолдыз кебек якты чагы,
Хисләремнең энҗе кебек затлы чагы,
Иреннәрнең җиләк кебек татлы чагы —
Гомеремнең яшьлек дигән атлы чагы...

* * *

Кемдер көткән — вакытында килмәгәнбез,
Иң изгеләр көткәнлеген белмәгәнбез,
Йөрәк сүзен колакка да элмәгәнбез,
Газизләрне чит яклардан эзләгәнбез...

* * *

Очкын гына иде күңел түремдә —
Син учак иттең сулышың өрдең дә,
Үзең кабызган учакны хәзер инде
Гомер буе дөрләт шулай, сүндермә!

* * *

Бакчаларда алмагачлар чәчәк аткан,
Ботагына кунып сайрар кошлар кайткан,
Сайрар кошлар үз тирәген эзләп тапкан —
Мин табармын икән сине, җаныем, кайчан?!

* * *

Сиңа биргән вәгъдәләрем исемдә —
Онытмадым мин аларның берсен дә,
Безнең гомер алда әле, вәгъдә бирәм
Үтәрмен дип барысын да, күрсенмә!

* * *

Мин дә беркөн әйләнермен тузанга,
Очып китәрмен җиләс җил тузганда
Һәм ятармын синең барыр юлларыңа —
Сизәрсеңме яннарымнан узганда?

* * *

Очрадың да хисләремне кол иттең,
Утка салып йөрәгемне көл иттең,
Мең рәхмәтле шуның өчен сиңа мин —
Күңел бакчамны чәчәк тә гөл иттең.

* * *

Хәтерлимсең, бутый-бутый кәгъбәләрне
Алларыңда минем кылган сәҗдәләрне?
Кәгъбәм булып калдың миңа гомер буе,
Онытсам да кайбер биргән вәгъдәләрне...

* * *

Язмышлар бит була алмый туры гына —
Туры була бары кояш нуры гына,
Кояш нуры хәтта кереп буталанган
Түшләреңнән сузылып төшкән толымыңа.

* * *

Иреннәрең, тоям, беркем үпмәгән,
Үргән толымнарың беркем сүтмәгән —
Шушы мәллә, Раббым, минем язмышым
Төшләремдә хәтта өмет итмәгән...

* * *

Алларымда Зөһрә булсаң, Таһир мин,
Сөю бакчасында йөргән бахыр мин,
Мәхәббәтем кире какма, гүзәлем,
Мәҗнүн кебек акылымнан шашармын.

* * *

Төннәрне ялгадык без икәү таңнарга,
Озаттык хыяллар, салдык та салларга,
Нәсихәт укыды сандугач төн буе
Кунды да баш өсте ярдагы талларга...

* * *

Очкын чыкмый бәрми торып ташка ташны,
Чара юк дип бәреп булмый ташка башны,
Әй җанашым, аңлашырбыз, бер серләшик,
Бер гөрләшик әле куеп башка башны!

* * *

Кемнәр газап чикмәгән соң сөюдән,
Сөюләрен әйтә алмый көюдән...
Йөзләреңә карарга да шикләнәм —
Куркам сиңа үз күзләрем тиюдән.

* * *

Күзләреңә бактым — күзем алалмадым,
Тик әйтергә сүзләр генә табалмадым,
Алдыбызга өзелеп төште кызарып пешкән
Бер алмасы бакчадагы багалманың...

* * *

Күзләремә җитми синең зифа сының,
Күңелемә җитми синең шифа-җылың,
Таң җилләре кагылса да өзәр кебек
Юксынудан киерелгән күңелем кылын.

* * *

Моңсу гына карап торам суларга,
Шашкан дулкын килеп сеңде сул ярга,
Дулкын булсам, шашып килеп яннарыңа,
Онытылып сыеныр идем син ярга...

* * *

Ничә мендем чиксез сөю күкләренә,
Сер бирмәдем чибәрләрнең күпләренә,
Үзең — тиңсез, күзең — диңгез, җаныкаем,
Төшеп баттым шул диңгезнең төпләренә...

* * *

Хисләремне бәйләп куйдым арканга,
Ычкындылар бары да синең арканда,
Исәрләнгән хисләремне барлап йөрим
Унсигез яшь болыныма кайтам да...

* * *

Көтмәгәндә күзләремә чалындың
Хатирәсе булып үсмер чагымның,
Шуннан бирле үсмер чактан аерылалмыйм —
Рәте китте бу тымызык җанымның.

* * *

Тормыш юлларыннан атлап барган чакта,
Соңгы чиккә җитеп, иңрәп арган чакта,
Канатларым бөтенләйгә сынмасын дип,
Хыялларым яңартам мин синең хакта...

* * *

Аз булдымы төннәр — йокы кермәгән,
Бармы төнем — төштә сине күрмәгән,
Шул төшләрем ашса икән чынбарлыкка —
Ходай безгә андый бәхет бирмәгән.

* * *

Мин бит сине бер кабат та кочмадым,
Сине кочып галәмнәрдә очмадым,
Ә барыбер синең назлы җылыңны
Саклый әле минем ятим кочагым...

* * *

Сөйдем сине малайларча тилереп,
Хисләр аттым бәгыремне киереп,
Мәхәббәттә мәргән була алмадым мин —
Булмады ла йөрәгеңә тидереп...

* * *

Хыянәткә, ялганнарга ышанмадык,
Очабыз дигән хисләрне тышауладык,
Янәшәдә генә үтте ике гомер —
Хисләрне без әллә ничек кушалмадык.

* * *

Тәүге тапкыр күрдем сине хыялымда —
Хыялымның да бик ерак-ерагында,
Шул хыялга барып җитәр өчен
Ни җитмәде икән минем йөрәгемдә?!

* * *

Еллар үткәч кенә белдем, яраткансың,
Минем кебек яратудан җан аткансың...
Валлаһи, дим, бу язмышны, тотып алып,
Аягыннан егылганчы яңакларсың!

* * *

Дөньялыкта калмады һич бурычым —
Чәчтем, урдым һәм бурадым бурыйсын...
Нәфес дәшә күңелнең иң түреннән —
Татыдыңмы сөюнең иң олысын?

* * *

Бу күңелләр һаман шулай сабый ла,
Чәчәк күрсә, гел керфеген саный ла,
«Сөя», дигән фал чыга гел, багышласам
Шул чәчәкне җитмеш яшьлек җаныйга.

* * *

Бу мәхәббәт дигәннәре алма икән,
Икәү бергә авыз итми калма икән,
Шул алмалар үсә торган бакчаларның
Ишекләре, ачкычлары кайда икән?..

* * *

Тик йолдызлар гына безне күргән иде,

Сер сакларга безгә вәгъдә биргән иде,
Йолдызлар да серне саклый белми икән —
Безнең серне бөтен авыл белгән инде...

* * *

Нигә тиңлим карашыңның үткенлеген?
Язгы гөрләвек тавышы кеткелдәвең,
Үбә-үбә кемнәр генә санар икән
Язгы кояш сипкән чая сипкелләрең?!

* * *

Яраткачтын түзә күңел йөгәнләүгә,
Иртә-кичен әкрен-әкрен игәүләүгә...
Юк, барыбер көнләшмим мин гомер буе
Йөгән күрми, игәү күрми йөргәннәргә.

* * *

Шикле итеп чылтырады капка биге,
Уянгандыр әнкәеңнең күңел шиге,
Тик әткәең авыр сулап куйгандыр,
Кагылып үткәч күңеленә яшьлек җиле...

* * *

Карыйм да мин синең чая күзләреңә,
Күзеңдәге ат тоягы эзләренә,
Гаҗәпләнәм үз-үземнең гомер буе
Шул күзләрнең ялкынына түзгәненә.

* * *

Гомер буе кешеләргә акыл саттым,
Өлкәнәеп җиткәч кенә акыл таптым:
Бик ерактан эзләгәнем янәшәмдә —
Алтын балыктан да алтын минем хатын.

* * *

Күзләремә нигә шикле карыйсың,
Хисләремне кабат-кабат тарыйсың?
Алдасам да, ул риясыз, керсез генә,
Әллә мине гөнаһлыга саныйсың?..

* * *

Бер мәхәббәт җитә безнең икебезгә —
Шул ялкында җылынабыз икебез дә.
Шулай диеп юанырсыз әле сез дә
Минем кебек җитмеш яшькә җитегез дә...

* * *

Карап йөр, дип, юлларыңда як-ягыңа,
Әткәй киңәш бирә иде яшь чагымда,
Үти алмыйм, әткәй, синең киңәшеңне —
Ошамый бит шул гадәтем аппагыма!

* * *

Яр, яр, диеп җиттек гомер ярына,
Аска баксаң, йөрәккәйләр ярыла,
Ярый әле янда гомер иткән ярлар —
Шөкер итик инде, туган, барына!

* * *

Сине сөеп сүз әйталмый йөргәндә,
«Сөяме», дип фал салдырдым чегәнгә.
Җавап бирде: язмыш дигән тулпар атның
Кай якка каравы бәйле йөгәнгә!

* * *

Мин ышандым синең «сөям» дигәнеңә
(Кемгә ышаныйм, ышанмыйча сөйгәнемә!),
Син алдадың, мин алдандым, ахры, җаный,
Эләктем бит синең каеш йөгәнеңә...

* * *

Җырлый-җырлый сандугач та картаямы?
Унсигездә күзең төшкән яр каямы?
Кинәт кенә шул сораулар килде башка —
Әллә инде минем баш та «янтаямы»?!

* * *

Бу төнне дә озатып куйдым «к чертям» —
Гашыйкларга бигрәк авыр кич-иртән...
Минем хәлне белгән кебек койма астыннан
Мыштым гына карап тора кычыткан.

* * *

Гашыйк булдым сиңа, җаным, чамасыз,
Сөюемне әйтә алмыйм — чарасыз,
Үзең башлап бер сүз катсаң, гомерлек
Колың булып яшәр идем, каракүз!

* * *

Күкрәгеңә тамды тамчы — эреп бетте,
Әллә инде йөрәгеңә кереп китте,
Шул тамчыдан көнләшкәнне сиздә бугай —

Яннарымнан күрше эте өреп үтте...

* * *

Изге булган сине тудырган ай-камәр —
Чибәрлекне биргән инде шуның кадәр!
Унбиш көндә ай күк юкка чыгыйммыни,
Күзем төште сиңа, түзим соң ни хәлләр?

* * *

Янәшәңдә кемдер атлый — мин түгел,
Аңлыйм инде, сиңа безләр тиң түгел,
Илаһи зат, алма битең уртасында
Ни өчен мин бер кечкенә миң түгел?!

* * *

Йөрәгемнең шыр буш чагы — кер булмаса,
Җылы сулышыңны җанга өр булмаса,
Синең йөрәгеңдә миңа урын бармы —
Җавап бирче, җаныкаем, соң булмаса!..

* * *

Үз ярын эзләгән ярлар тапсын гына,
Сөю утларына кереп батсын гына,
Эзләп-эзләп тә үз ярын тапмаганга
Ярдәм итсә итәр доктор Ватсон гына.

* * *

Берәм-берәм ача җаныем серләрен,
Гөнаһлы икән минем кашы сөрмәлем —
Күз-кашына сөрмә тартып маташканда,
Сирпеп алды кемгә икән күзләрен?..

* * *

Соң, дисең син, аңла инде акыл белән,
Акыл дигән нәрсә миндә такыл, беләм,
Тик шулай да бер киңәшеп алыйм димен
Синең кебек таш бәгырьле Җаһил белән...

* * *

Мин дә китәрмен дөньяны калдырып,
Минем белән бергә китмә, кал берүк,
Телеграмм биреп үзем чакыртырмын,
Фатир алып, яңа гараж салдырып.

* * *

Бәхетнең иң олысына ирешеп,
Йөргән идек ак вәгъдәләр бирешеп,
Хәзер бергә үтә көннәр берәм-берәм,
Ике күрше эте кебек өрешеп...

* * *

Мәхәббәт җырлары яздым күп итеп,
Мәхәббәт белгече булган күк итеп,
Үзенә дип уйлагандыр, укыды да
Хатын суырып үбеп алды чүт итеп.

* * *

Гомер буе сөю диеп янабыз,
Чибәрләрне күрсәк арттан чабабыз,
Сөю китә, гүзәл кала, үзебез
Сөю дигән шул тозакка кабабыз...

* * *

Мәхәббәттә һәркемнең дә үз юлы,
Мәхәббәткә илтә торган юл — олы,
Мәхәббәткә сусаганнар, ашыгыгыз,
Быел бездә татлы мәхәббәт елы!

* * *

Карашларың синең минем җанга бәлзәм,
Озата бара мине һәрчак кайда барсам,
Карашыңны синең якты маяк итеп,
Юл табармын ялгыз сахраларда калсам.

* * *

Җаныңны ябышкак пәрәвез сарганда,
Йөрәкне сагышлар кырыкка ярганда,
Тотына хәтерем үткәнне барларга —
Кайта да сыена тәүге пакь ярларга.

* * *

Бакчамдагы тәүге шыткан гөлем сиңа,
Гөрләп килгән шаулы язлар телим сиңа,
Гөрләп килгән, шаулап килгән шул яздагы
Җылы ләйсән яңгыр булып килим сиңа!

* * *

Мәхәббәт дип өзгәләнә күп ирләр —
Аның өчен башын сала яугирләр!
Тик барыбер мәхәббәт дип тибә йөрәк,
Алар өчен сызланса да бәгырьләр.

* * *

Бакчаң тулы пешеп килгән йөзем икән,
Үрелеп кенә учлап-учлап өзим микән,
Вакыт җитеп, изрәп пешеп учларыма
Берәм-берәм коелганчы түзим микән?!

* * *

Гомер мизгелләрен чәчеп калдырып,
Йөргән чакта дөнья буйлап каңгырып,
Рәхмәт сезгә, дөнья гамен оныттырган
Асыл затлар, йөрәкләрне яндырып.

* * *

Булсаң иде син бер божыр, мин — лачын,
Каршыңа ташланыйм җәеп колачым...
Уйларымны сизде, ахры, миңа карап
Елмайды хәтерләтеп май кояшын!

* * *

Җанымда юк бернинди дә үкенечем,
Бар сиңа тик бер кечкенә үтенечем —
Минекедәй башкаларның җанын кыйма,
Зинһар, димен, әй рәхимсез «үтерүчем»!

* * *

Чибәрләрне күрсәм, йөрәк канатлана.
Акыл әйтә, җитте сиңа, кабатлама!
Әй акылым, бу соңгысы, бүтән булмас,
Монысы өчен генә тотып яңаклама!

* * *

Миңа синнән бик аз гына наз кирәк,
Табигатьтән елга хет бер яз кирәк...
Шулардан да мәхрүм итсәң, и Ходам,
Хур кызлары янына юллама яз тизрәк!

* * *

Сез кайларда икән хәзер, асыл затлар,
Күптән инде алганым юк сездән хатлар,
Йоклый алмый яткан чакта төннәр буе
Исегезгә төшәме соң теге чаклар?..

* * *

Гашыйк булдым кыйгач кара кашларыңа,

Хуҗа булалмадым исәр башларыма...
Бу халәттә сиңа бер юл, и Гарифҗан,
Шул кара каш кочагына ташланырга!

* * *

Сөям, диеп, җаныкаем, үлеп булмый,
Тәкъдир язмаган хәлләрне күреп булмый,
Беләм сөю бакчасының кайдалыгын —
Кулларымда ачкычы юк, кереп булмый.

* * *

Яши-яши меңьеллык тут та ава,
Ил башлыгы сәрдарга да юк дәва...
Тирә-якта күпме чибәр, күзең ач,
Сау чагыңның кадерен бел, йоклама!

* * *

Синнән миңа әллә ни күп кирәк түгел —
Җылы караш кирәк, ачык күңел,
Шуларны да миннән артык күрсәң,
Гафу итә алмам сине мәңге, сеңел!

* * *

Тәүге хыялларга өрпәк канат булдың,
Ныгымаган канатлардан харап булдым,
Төпсез сөю күкләрендә очкан чакта
Башны бүтән югалтмаска сабак булдың.

* * *

Каян гына килеп чыктың каршыма,
Әллә былбыл оя корган кашыңа,
Күзләреңнән күз алалмый барган чакта
Сөртенеп егылдым юлның ташына...

* * *

Күзләреңә бактым ялгыш уйламыйча,
Синең күзләр җавап бирде соңламыйча,
Акыл хәзер гел битәрли бармак янап —
Читкә бакма, дидем, миннән сорамыйча!

* * *

Атлыйсың син урам буйлап кет-кет басып,
Карап калам артларыңнан авыз ачып,
Йә Ходаем, бу гүзәллек алиһәсе
Кайсы юеш борынга, дим, булыр насыйп...

* * *

Әйләндермә башны, җаным, юк белән,
Йөрәгем — ут, уйнама син ут белән,
Яулыйм дисәң күңелемне Амур ялла,
Атып алсын йөрәгемне ук белән!

* * *

Кайвакытта тыеп булмый бер хисеңне —
Тыеп кара, туганкаем, нәфесеңне...
Каян гына пәйда булдың, гүзәлкәем,
Билең нечкә, буй-сының, һай, нәфис инде!

* * *

Сөям, дидем, җаныкаем, алдамадым,
Син бит мине, панимаеш, аңламадың,
Чәлтерәтеп суктың минем яңагыма —
Әле дә булса кызыша бит алмаларым...

* * *

Җаныкайлар, җитте инде, азмагыз,
Тәкъва булып яши инде абзагыз,
Тик бер генә үтенечем бар сездән —
Ташлады, дип өстән жалу язмагыз!

* * *

Җиләк пешкән төпләрендә артышларның,
Шушы таудан җиләк җыеп кайтышларым,
Сизмәдем дә, белмәдем дә, җаныкаем,
Артыш төпләренә тартты кай төшләрең?..

* * *

Калфагым бар, җаныкаем, шәлем юк,
Бүләк итеп шәл алмыйча хәлең юк,
Ул алмады, бу алмады, теге алмады —
Инде сиңа ябышып чыкмый мәлем юк!

* * *

Челтер-челтер, челтер-челтер телефон,
Бу телефон миннән нәрсә тели соң?
«Сөям», дигән сүзең булгач, җаныкаем,
Нигә аны телефоннан сөйлисең?..

* * *

Үгетләмә мине, зинһар, гүзәлем,
Гүзәлләргә бакмый үзем түзәрмен,
Тик... гайрәте җитәр микән гүзәлләргә

Карамаска, ай-һай, минем күзләрнең?!

* * *

— Синең белән минем хакта ни диләр?
— Таһир белән Зөһрәләргә тиңлиләр!
— Таһир-Зөһрә сөюенең искелек
Икәнлеген белми микән, тиләләр!

* * *

Нур сибелә күзләреңнең карасыннан,
Атлауларың, күз тимәсен, лама сыман,
Ике күзем аерылмый синең арттан,
Мине ташлап мәңге китеп бара сыман...

* * *

Көтмәгәндә юлларымда очрадың,
Йөрәгемне телде керфек очларың,
Бәгырькәем, ник аларны шулкадәр
Җәрәхәтләрлек иттереп очладың?

* * *

Озын керфек, кыска итәк, йә Аллам,
Шуны күреп өнсез калды күз алмам,
Алма түгел, үрелеп кенә өзә алмам,
Үрелмичә дә, җанашым, түзалмам...

* * *

Син кемнеңдер өзелеп сөйгән ярымы?
Миңа таба күз дә салма, ярыймы!
Көнләшүдән эт иттереп бер кыйнармын
Сине сөйгән, сине кочкан «сабый»ны.

* * *

Нигә тоник, нигә моңсу Җидегән йолдыз —
Җиде йолдыз — берәм-берәм бары да ялгыз...
Ялгызлыктан йолдызлар да тоныклана,
Ялгызлыкка нокта куйыйк әйдә, балдыз!

* * *

— Безнең сөю без туганчы юралгандыр,
Чәчләр чәчкә туганчы ук уралгандыр...
— Ни сөйлисең, абзыкаем, башың пеләш,
Сөюләрең бәйдән китеп югалгандыр!

* * *

Ипле булып, тәкъва булып кыланмадым,
Арттырып үтәдем сөю планнарын,
Күпме сөеп-сөелеп тә аңламадым —
Сөю нәрсә була соң ул, оланнарым?!

* * *

Очрашкан юк синең белән күптән,
Утырган юк йолдыз санап күктән,
Аңлашырга сүз табалмый йөри торгач,
Безнең сөю кемгә ияреп киткән?

* * *

Син сүзләрне өстен күрдең хисләрдән,
Хисләр түгел, сүз үтерә, сүз — мәргән,
Нинди яра әрнеп ята йөрәгеңдә —
Тәкәббер күзләрең моңсу, үзгәргән?

* * *

Сөю көткән чагы иде күңелнең,
Бушап калган чагы йөрәк түремнең —
Асыл гөл дип исәрләнеп үрелдем,
Чүп үләне булып чыктың, сүрелдем...

* * *

Җилнең була таң җиледәй җылы, талгыны,
Була өзеп ала торган салкыны...
Күзләреңдә уйный синең поляр балкыш —
Әллә инде шул салкын җил шаукымы?!

* * *

Мактасалар мактасыннар, Зөбәйдә,
Таптасалар таптасыннар, түз әйдә,
Җаның сатып, тәнең сатып көн күрер чак,
Заман җиле уңаена йөз әйдә!

* * *

Бай табигать әллә нинди бизәкләргә —
Жәлләмичә сипкән хәтта бөҗәкләргә...
Чуар күбәләкләр оча чәчәк сайлап —
Син дә шулай үтәсең ич үзәкләргә!

* * *

Шәраб тулы касәләрнең зыңлавы...
Өмет тулы иреннәрнең ымлавы...
Мөмкинме соң мондый чакта акылыңның
«Тукта!» диеп кисәтүен тыңлавы!

* * *

Минем күзләр бакмый инде читләргә —
Читкә карап намусны ник чүпләргә?
Әллә инде уйларымны сизеп алды —
Әзер тора хатын шуны җөпләргә!

* * *

Мәхәббәт җырлары күбрәк яз, диләр,
Картлыкта да кирәк сөю, наз, диләр,
Хатын белән кайнанам һич тынгы бирми,
Әллә яшьлектә кылганың аз, диләр.

* * *

Шигең булса яз өстемнән шикаять —
Суд залында очрашырбыз, ниһаять,
Болай итеп аңлашалмый йөрүләрдән
Сиңа-миңа, бәгырькәем, ни хәят?!

* * *

Ай-һай куе булды синең тарагың,
Хисләремне кабат-кабат тарадың,
Тарый торгач җанда хис тә калмаган.
Ни дим инде сиңа, хисләр карагым?

* * *

Һич танырлык түгел синең кемлегеңне —
Бигрәк мулдан сылагансың иннегеңне,
Юкса үзең иннексез дә түтәлдәге
Күз явыңны ала торган сөмбел инде!

* * *

Синдә генә инде, җаным, характер,
Характерың сындырырмын, карап тор,
Үҗәтлегең сындыруның туры юлы
Өч мәртәбә кабатлаган «талак»тыр...

* * *

Горур гына янәшәмнән үтеп киттең,
Йөрәгемне әллә ничек өтеп киттең,
Күзләремнән югалганчы карап калдым —
Бер борылып карар диеп өмет иттем...

* * *

Бу тормыштан күпне алдым, туймадым,

Сабый кебек онытылып уйнадым,
Әй гүзәлләр, сез кайларда йөрисез —
Мин бит әле дога кылып куймадым!

* * *

Аз яндыкмы җанны өтәр утларда
(Карама икән ул күзе мутларга!).
Аһ бу күзләр, серле караш, татлы сүз —
Ашыкма, йөрәк, иртәдер туктарга!

* * *

Шатлык килсә, эчеп күңел ачабыз,
Кайгы килсә, хәмер белән басабыз —
Күңел касәләре һаман бушый бара,
Тик бушамый өстәлдәге касәбез...

* * *

Әйдә, туган, кабыз әле кальяныңны,
Тартып җибәр, сузып җибәр тальяныңны,
Тотып куй да касәләргә салганымны,
Таратыйк бер күңелдәге дәрья-моңны!

* * *

Өстәлләрдә касә тулы шәраб тора,
Күзен кысып, миңа гына карап тора,
Шәраб эчеп, хурлар кочып гомер итү
Өч мизгеллек бу дөньяда ярап тора.

* * *

Бар ул җирдә эзләгәнен тапканнар,
Бар тапканын бер чәркәгә сатканнар —
Яшәү гамен аңлый алмый чәбәләнеп,
Чәркә төпләренә төшеп батканнар...

* * *

Хәмер эчү гөнаһ, дидек, чыкты җае —
Өстәлләрдә хәмер түгел, арыш мае,
Арыш мае берәүгә дә харам түгел,
Әйдә, туган, салып җибәр, карышмале!

* * *

Үрелмәдек түгел без дә касәләргә
Азмы-күпме юнь барында кесәләрдә
(Объективка язган чакта кирәк булыр,
Болай мине ипле, тәкъва дисәләр дә...).

* * *

Хәмер дигәннәрен сөймим, начар исем,
Үзе ярый кайчак телне ачар өчен,

Күңелдәге сыктауларны басар өчен,
Җан өшеткеч ялгызлыктан качар өчен...

* * *

Тотыйк әле касәләрне, әйдә, туган,
Күрми торыйк изге айны яңа туган,
Тәкъдир беркөн барысына да бирер бәя
Һәм каптырыр сырхау дигән әче суган...

* * *

Кичтән мине кайнар шәраб бөркет итә,
Иртәгесен бөркет баскан көртлек итә,
Таңнан кабат бөркет булу җаен эзләп,
Күкрәкләргә сыймый йөрәк, дөп-дөп итә...

* * *

Мин бит инде бу тормышта сабаклы —
Тешли алмый һәрбер өргән сабакы...
Тукта, туган, сүзем бүлдең вакытсыз,
Күрми үтеп китәсең ич кабакны!

* * *

Касәләргә тутыр шәраб, туган, мәйтәм,
Касәләрнең төпләрендә бии шайтан,
Шул шайтан күк бии-бии урам буйлап,
Уңга-сулга сәлам биреп өйгә кайтам.

* * *

Салып кайтып бара идем кич җиткәндә
(Сөйләмим һич бары телем кычытканга),
Егылып кына калсам, туган, ярар иде,
Туры килдем сукмактагы кычытканга.

* * *

Уң кул белән кочаклаган фахишәсен,
Сулы белән кысып тоткан «ак» шешәсен,
Ана сөте белән аңа кергән тик шул гына,
Башка ямен күрми җирнең, аһ, нишләсен...

* * *

Яшь чагыннан сөйгәне бер шәраб булды,
Шул сөйгәне куенында харап булды,
Бер уйласаң, күпмеләрнең харабына
Шәраб дигән кайнар туташ сәбәп булды.

* * *

Әйтәм әле күршемдәге Гарәфине —
Анда-монда күп ташыды «гәләфи»не,
Сәләт ягы көнләшерлек булмаса да,
Иярләде шактый биек кәнәфине...

* * *

Һаваларда очып бара пар-пар аккош,
Офыкларда уйнап тора чуар балкыш,
Баш төзәтер чара тапмый чат башында
Газаплана иртә таңнан ике алкаш.

* * *

Бушап калган өстәлдәге касәләр,
Өстәл астында тәгәри шешәләр,
Баш чатнавын басар өчен һич чара юк —
Аек чаклар үртәп искә төшәләр...

* * *

Әйдә, туган, буш тотма син касәләрне —
Бер хушланыйк бушатканчы кесәләрне,
Бушап калса әгәр инде кесәләр дә,
Сатып эчәрбез бушаган шешәләрне...

* * *

Кырык градус күрсәтә термометр —
Кырыклыны, әйдә, туган, монда китер,
Кабар өчен ярты телем сохари бар,
Кетер-метер, кетер-метер, кетер-метер...

* * *

Игътибарга алдым ничә мәртәбә —
Әйләнә дә кайта сүзең чәркәгә,
Шул чәркәдә күңелеңне чайкап кына
Көч табасың яшәү өчен иртәгә...

* * *

Сөртенгән саен чаттагы баганага
Сылтама син сәрхушлегең заманага —
Заманасы нинди генә булганда да
Сөртенергә багана бар томанага.

* * *

Зәгъфран сарылары йөзеңдә,
Теге чакның эзе дә юк күзеңдә,
Без дөньяда мәңгелек, дип йөргән идең —
Ник тормадың әле, туган, сүзеңдә?!

* * *

Туры юлга әйдәп була адашканны,

Хак юлга көндерәм димә алдашканны,
Уңны — сулдан, сулны уңнан аералмый
Үз иманын башка белән алмашканны.

# Эчтәлек


Гамьле шагыйрь бакчасы. *Р.Фәйзуллин* ..............................

Укучыма бер сүз. *Г.Мөхәммәтшин* ......................................

Бер уйласаң, бу тормышта бары да гади —
Берәү Мәҗнүн, берәү Нәби, берәү Гали... ............................

Борынгыдан безгә мирас кыйммәтләр бар,
Тәңре безгә бүләк иткән нигъмәтләр бар... ..........................

Бар кешене тиңләдем мин игезләргә —
Омтылдым гел бу дөньяны тигезләргә.................................

Бу дөньяга туа кеше яшәр өчен,
Бар дөньяга, мин тудым, дип дәшәр өчен... ..........................

Ирләр булып туганбыз без чыдар өчен,
Мәйданнарның уртасына чыгар өчен...................................

Татар булып туганыма сөенәм —
Үз телемә, үз моңыма сыенам...............................................

Балачакка кайтып киләм көн дә бер,
Балачагым, кыйблам минем синдәдер..................................

Мәңге яшәр империя тумаган,
Бу җиһаттән безнең бәхет булмаган... ..................................

Салды башны бу мәхәббәт сәмумнарга,
Буйсындырды әллә нинди кануннарга... ..............................

Өстәлләрдә касә тулы шәраб тора,
Күзен кысып, миңа гына карап тора... .................................



Литературно-художественное издание

***Мухаметшин** Гарифзян*
*(**Мухаметшин** Гарифзян Садыйкович)*

## В саду рубаи

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Мөхәммәтшин** Гарифҗан*
*(**Мөхәммәтшин** Гарифҗан Садыйк улы)*

## Робагыйлар бакчасы

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректоры *Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.11.2007. Форматы 60г90 1/32. Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,0. Шартлы буяу-оттиск 6,25. Нәшер-хисап табагы 3,92.
Тиражы 2000 д. Заказ С-1322.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААЖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.